**УПРАВЛЕНИЕ ОБРАЗОВАНИЯ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОДА КАЗАНИ
ОТДЕЛ ОБРАЗОВАНИЯ ПО АВИАСТРОИТЕЛЬНОМУ И НОВО-САВИНОВСКОМУРАЙОНАМ
МУНИЦИПАЛЬНОЕ БЮДЖЕТНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ ДОПОЛНИТЕЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЦЕНТР ДЕТСКОГО ТВОРЧЕСТВА»
НОВО-САВИНОВСКОГО РАЙОНА г. КАЗАНИ**

| | |
|---|---|
| Принята на заседании<br>педагогического совета<br>Протокол № 1<br>от «01» 09 2022 года | «Утверждаю»<br>Директор МБУДО ЦДТ<br>______ Медведева М.Н<br>Приказ № 38 от «06» 09 2022 г. |

# ДОПОЛНИТЕЛЬНАЯ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ ОБЩЕРАЗВИВАЮЩАЯ ПРОГРАММА
**«Осталыкка биш баскыч»
(Пять ступеней мастерства)**

**Направленность**: художественная
**Возраст учащихся**: 7-16 лет
**Срок реализации**: 5 лет

**Автор-составитель:**
Якупова Сирина Алмазовна
педагог дополнительного образования

**Казань - 2011**

**Эчтәлек**

1. Пояснительная записка (на русском языке) ________________________________ 3 стр.

2. Аңлатма _________________________________________________________________ 6 бит

3. Беренче уку елы программасының эчтәлеге һәм укыту-тематик планы_______ 12 бит

4. Икенче уку елы программасының эчтәлеге һәм укыту-тематик планы _______ 14 бит

5. Өченче уку елы программасының эчтәлеге һәм укыту-тематик планы _______ 17 бит

6. Дүртенче уку елы программасының эчтәлеге һәм укыту-тематик планы _____ 19 бит

7. Бишенче уку елы программасының эчтәлеге һәм укыту-тематик планы _____ 21 бит

8. Программаны гамәлгә ашыруның оештыру-педагогик шартлары ____________ 23 бит

9. Кулланылган әдәбият исемлеге__________________________________________ 23 бит

10. Кушымта ____________________________________________________________ 24 бит

## Пояснительная записка

Настоящая программа имеет **художественную направленность.** Программа является модифицированной, разработана на основе типовой учебной программы «Театральный кружок», утвержденной МО СССР в 1986 году, а так же на основе авторских программ: В.Н.Букатов, А.П.Ершова «Актерская грамота»; А.И.Фоминцев «Уроки основ театрального искусства в начальных классах общеобразовательной школе»; Пузанова Л.А. «Мир театра»; Рихтер Ю.Ю. «У моста».

Настоящая программа разработана в соответствии с основными нормативными документами:

1. Федеральный закон об образовании в Российской Федерации от 29.12.2012 №273-ФЗ;
2. Распоряжение Правительства РФ от 31 марта 2022 г. N 678-р «Об утверждении Концепции развития дополнительного образования детей до 2030 г. и плана мероприятий по ее реализации»;
3. Федеральный проект «Успех каждого ребенка» в рамках Национального проекта «Образование», утвержденного Протоколом заседания президиума Совета при Президенте Российской Федерации по стратегическому развитию и национальным проектам от 3.09.2018 №10;
4. Приказ Минпроса России от 3.09.2019 №467 «Об утверждении Целевой модели развития региональных систем дополнительного образования детей»;
5. Приказ Министерства просвещения Российской Федерации от 9.11.2018 №196 «Об утверждении Порядка организации и осуществления образовательной деятельности по дополнительным общеобразовательным программам»;
6. Приказ Министерства образования и науки Российской Федерации от 23.08.2017 №816 «Об утверждении Порядка применения организациями, осуществляющими образовательную деятельность, электронного обучения, дистанционных образовательных технологий при реализации образовательных программ»;
7. СП 2.4. 3648-20 «Санитарно-эпидемиологические требования к организациям воспитания и обучения, отдыха и оздоровления детей и молодежи», утвержденные Постановлением Главного государственного санитарного врача Российской Федерации от 28.09.2020 г. №28;
8. Устав образовательной организации.

*Новизна* образовательной программы состоит в том, что она направлена не только на когнитивное развитие ребенка (развитие всех видов мыслительных процессов, таких как восприятие, память, формирование понятий, решение задач, воображение и логика), но и на создание атмосферы эмоционального благополучия ребенка.

*Актуальность* программы обусловлена тем, что в эпоху глобализации на первое место выходит проблема формирования новых представлений о культурных ценностях. Она продиктована складывающимися социальными условиями, требующими от человека определённых способностей для адаптации в окружающем мире. Занятия театральным творчеством помогают ребятам приобретать жизненный опыт, развивать творческое отношение к действительности. Они приобретают уверенность в своих силах.

*Педагогическая целесообразность*: Художественно-эстетическое образование детей средствами театрального творчества способствует решению ряда учебных задач: обучению живой разговорной речи, приобретению известной свободы в обращении, умению выступать перед аудиторией в качестве ораторов. Воспитание театром формирует мировоззрение, эстетический вкус, пробуждает самостоятельное и независимое мышление.

***Цель программы*** – создать условия для воспитания творчески активной, свободной личности, способной жить в гармонии с самим собой, природой и окружающими людьми, раскрытия способностей и талантов детей средствами театрального искусства, организации их досуга путем вовлечения в театральную деятельность.

***Задачи программы:***

*Обучающие:*

- приобрести необходимые знания о театральном искусстве;
- приобрести актерские навыки – умение взаимодействовать с партнером, создавать образ героя, работать над ролью;
- научить через упражнения из области актёрского мастерства концентрировать внимание, управлять фантазией, обладать образным видением, анализировать и владеть психофизическим состоянием;
- через игровые и тренинговые упражнения помочь избавиться от излишних психологических зажимов и комплексов;
- обучить детей элементарным навыкам речевой культуры при помощи специальных заданий и упражнений на постановку дыхания, дикции, интонации;
- выработать умение пользоваться правильным литературным произношением, согласно современным нормам русского языка;
- приобрести практические навыки пластической выразительности с учетом индивидуальных физических возможностей ребенка.

*Развивающие:*

- развить интерес к специальным знаниям по теории и истории театрального искусства;
- развить творческие и актерские способности;
- развить эстетическое восприятие, художественный вкус, творческое воображение;
- развить речевой слух, внимание и память;
- развить коммуникабельность, дисциплинированность, организаторские способности, умение преподнести и обосновать свою мысль.

*Воспитательные:*

- воспитать чувство ответственности, коллективизма, трудолюбие, активность, доброжелательность, уважение к творчеству других;
- формировать этические нормы поведения, способность работать в коллективе и подчиняться общим правилам;
- воспитать умение критически оценивать, как свою работу, так и работу своих товарищей.

*Форма реализации программы* – очная, в особых обстоятельствах допускается реализация образовательной программы или ее части с применением электронного обучения, дистанционных образовательных технологий. При электронном обучении с применением дистанционных образовательных технологий продолжительность занятия регулируется нормами СанПиН, принятых при работе учащихся за компьютером.

*Режим занятий:* Дети занимаются 2 раза в неделю по 2 академических часа. Всего на год отводится 144 часа. При электронном обучении с применением дистанционных образовательных технологий продолжительность занятия регулируется нормами СанПиН, принятых при работе учащихся за компьютером.

*Срок реализации программы* – 3 года, 432 часа. Дополнительная общеобразовательная общеразвивающая программа реализуется в течение всего календарного года, включая каникулярное время. При выполнении дополнительной общеобразовательной общеразвивающей программы организуется работа в пришкольных лагерях, проводятся воспитательно-образовательные мероприятия. В театральный коллектив принимаются все желающие в возрасте 8-16 лет. Число участников каждой группы не менее 15 человек.

***Ожидаемые результаты:***

К концу ***первого года*** обучения дети должны

*знать:*

- основные правила техники безопасности и поведения на занятии;
- как сочинять этюды по сказкам, басням;

- навыки действий с воображаемыми предметами;
- как находить ключевые слова в отдельных фразах и предложениях и выделять их голосом;

*уметь:*

- общаться со сверстниками и взрослыми в разных ситуациях;
- быть эмоционально раскрепощенным, чувствовать себя комфортно в любых жизненных ситуациях;
- быть доброжелательными и контактными;.
- планировать свои действия в соответствии с поставленной задачей, условиями её реализации.

К концу ***второго года*** обучения дети должны

*знать:*

- различные виды театра;
- точки зала;
- как пользоваться интонацией, выражающими разнообразные эмоциональные состояния (грустно, радостно, сердито, удивительно, жалобно, презрительно и т. п.);
- как пополнять словарный запас;
- образный строй речи;

*уметь:*

- планировать, контролировать и оценивать актерские действия в соответствии с поставленной задачей и условиями её реализации;
- определять наиболее эффективные способы достижения результата;
- слушать собеседника и вести диалог;
- признавать различные точки зрения и право каждого иметь и излагать своё мнение и аргументировать свою точку зрения и оценку событий.

К концу ***третьго года*** обучения дети должны

*знать:*

- элементарные сведения по анатомии человека.
- как выполнять ритмические упражнения с заданием;
- как выполнять перестроение в соответствие с заданием;
- элементы разученных постановок;
- как построить связный рассказ о своих впечатлениях от увиденного, сравнивая с предшествующими впечатлениями;
- *уметь:*
- сочинять небольшой рассказ на заданную тему;
- менять по заданию педагога высоту и силу звучания голоса;
- произносить скороговорки и стихотворный текст в движении;
- прочитать наизусть стихотворный текст, правильно произнося слова и расставляя логические ударения.

К концу ***четвертого года*** обучения дети должны

*знать:*

- простейшие этюдные формы;
- основные позиции рук и ног, держать осанку;
- как ориентироваться в пространстве;
- способы эмоционального отклика на художественные произведения;
- основы этики и эстетики сцены;
- основы здорового образа жизни.

*уметь:*

- ориентироваться в пространстве;

- равномерно размещаться на сценической площадке;
- двигаться в заданном ритме;
- на сцене выполнять свободно и естественно простейшие физические действия;
- произвольно напрягать и расслаблять отдельные группы мышц.

К концу ***пятого года*** обучения дети должны

*знать:*

- основы актёрского мастерства;
- приемы выполнения этюдных форм и пластических упражнений;
- основы сценической речи;
- способы перестроения;
- приемы импровизации;

*уметь:*

- владеть элементарной терминологией театрального искусства;
- владеть навыками саморегуляции, самоконтроля;
- владеть навыками согласованных действий в группе;
- фантазировать и воображать;
- пользоваться навыками культурной речи.

**Анлатма**

Балалар һәм театр - аларны туганнар диярсең! Балаларга да, театрга да фантазиягә, идеалга, һәм, әлбәттә, уенга омтылыш хас. Юкка гына К.С.Станиславский: "Балалар – иң яхшы актёрлар", дип бер генә кат әйтмәгәндер.

Әлеге программа үз эченә *сәнгати-эстетик юнәлешне* туплаган. Әлеге программа модификацияле булып санала, түбәндәге автор программалары нигезендә эшләнгән: В.Н.Букатов, А.П.Ершова "Актёрлык грамотасы"; А.И.Фоминцев "Гомуми урта белем бирү мәктәпләренең башлангыч сыйныфларында театраль сәнгать нигезләре дәресләре"; Пузанова Л.А. "Театр дөньясы"; Рихтер Ю.Ю. "Басма янында".

Программа 2012нче елның 29нчы декабрендә чыккан "Рәсәй Федерациясендә белем бирү турындагы" (№273-ФЗ 29.12.2012)Федераль Законга, Рәсәй Федерациясенең "Белем бирү үсеше" Дәүләт программасы (2013-2020нче елларга), РФ Мәгариф һәм фән Министрлыгының "Өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча укыту эшчәнлеген оештыру һәм тормышка ашыру тәртибен раслау турындагы" карары (№1008 29.08.2013), Санитар-эпидемиологик кагыйдәләр һәм нормативлар СанПиН 2.4.3172-14(Рәсәйнең ЮстМин-да 2014нче елның 20нче августында теркәлгән №33660), 2014-2020нче елларга балаларга өстәмә белем бирү үсеше Концепциясе (РФ Хөкүмәте күрсәтмәсе нигезендә №1726-р 2014елның 4нче сентябреннән), РФ Мәгариф һәм фән Министрлыгының " Өстәмә тулаем үсеш бирүче программаларын (төрле дәрәҗәдәгеләрен дә кертеп) проектлаштыру буенча методик рекомендацияләрнең юнәлешләре турындагы" (18.11.2015) Хат, РФ Мәгариф һәм фән Министрлыгының Яшьләр сәясәте, балаларны тәрбияләү һәм социаль яклау Департаменты хатына " Балаларга өстәмә белем бирү программаларына якынча таләпләр турындагы" кушымта (11.12.2006нче елдан, №06-1844), Балалар иҗат үзәге Уставына нигезләнеп эшләнгән.

*<u>Яңалык.</u>*Укыту программасының яңалыгы, баланың когнитив үсешенә(фикер йөртү процессының, хәтер, төшенчәләр формалашу, күзаллау, логика кебек барлык төрләренең үсешенә) генә юнәлтелмичә, бала өчен эмоциональ яктан уңышлы булган атмосфера тудыруга да юнәлтелгән булуында . Театр нигезләренә өйрәткәндә, психологик уен тренинглары актив кулланыла. Ул баладан "универсал актёр" ясамый, ә бәлки, психологик яктан төрле стресслы ситуацияләргә әзер булучы, тормышка җайлаша белгән кеше тәрбияли.

*<u>Актуальлелеге:</u>* Глобализация эпохасында беренче урынга мәдәни кыйммәт турындагы яңа күзаллауларның формалашу проблемасы чыга. Хәзерге заман мөхите күтәренке мәглүмати чараларга ия булучы, катлаулы динамик, югары көндәшлелек булган

мөхиткә әверелде. Шул ук вакытта, аңа культура һәм этнокультура даирәләренең күптөрлелеге хас, һәм аларда ориентлаша белү бик мөһим. Нәкъ менә монда балага тормышчан ситуацияләрнең театраль моделе ярдәмгә килә дә инде. Әлеге программа өстәмә белем бирү чаралары ярдәмендә, бер үк вакытта баланың гомуммәдәни үсешенә дә булышлык итеп, милли, рус, чит тел әдәбиятын өйрәнүдәге пробелларны өлешчә компенсацияләргә дә мөмкинлек бирә.

Программаның актуальлеге кешенең әйләнә-тирә мөхиттә җайлашуы өчен кирәкле аерым сәләтләре булуын таләп итүче социаль шартлар барлыкка килүдән туа.Театр сәнгате дәресләре балаларга тормыш тәҗрибәсе тупларга, чынбарлыкка карата иҗади мөнәсәбәтләрен үстерергә ярдәм итә. Аларда үз көчләренә ышаныч барлыкка килә. Ә бу исә, кешенең психологик сәламәтлеген тәшкил итүче бик мөһим нәрсә. Алар театрдан барысын да ала: яхшылык, гаделлек, мәхәббәт, күркәмлек, тәрбиялелек дәресләре. Ә болар, билгеле булганча, киләчәктә кешене кеше итеп танытучы иң төп тормыш дәресләре. Балалар үз-үзләрен танырга өйрәнә!

Театр – коллектив сәнгать. Театр дәресләре тәртипкә өйрәтә, хезмәткә мәхәббәт, кыюлык, җаваплылык, коллективизм хисе тәрбияли, үз фикерләрен җиткерә белүдә аерым күнекмәләр бирә. Шулай итеп, театр балаларда хезмәти һәм сәнгати тәрбияне тулаем берләштерә.

*Педагогик максатчанлык:* Балаларга театр сәнгате чаралары ярдәмендә әдәби-эстетик белем бирү кайбер укыту мәсьәләләрен чишәргә ярдәм итә: тере сөйләм телен өйрәтү, мөрәҗәгать итүдә билгеле ирекле лек булдыру, аудитория каршында оратор сыйфатында чыгыш ясый белү һ.б. Театр ярдәмендә тәрбияләү дөньяга караш, эстетик зәвык формалаштыра, мөстәкыйль фикер йөртергә өйрәтә. Театр берләшмәсендәге дәресләр өстәмә белем бирү шартларында белем бирү-тәрбия процессының сыгылма төзелеш мөмкинлеген, эшчәнлек төрләренең алышынып торуын, һәр баланың сәләтен индивидуаль ачуда киң мөмкинлекләр булуын күзаллый.

*Әлеге укыту программасын аерып торучы үзенчәлекләр:* Әлеге программа В.Н. Букатов һәм А.П. Ершова тарафыннан социоуен алымнарын кулланып эшләнгән театраль педагогикага нигезләнгән. Дәресләрне төзегәндә кечкенә төркемнәрдә эшләү куллныла, бу исә барлык балаларга да төрле позицияләрдә катнашырга мөмкинлек бирә: лидерлыкның, “педагог-тәрбияләнүче” роль функцияләренең алмашынуы. Укыту эшчәнлеге, проблемалы ситуацияне тудырып һәм чишеп, балалар бер-берсен үзара өйрәтерлек, мәгълүмат белән алмашырлык итеп оештырылган.

***Программаның максаты*** – үз-үзе, табигать һәм тирә-юньдәге кешеләр белән гармониядә яшәргә сәләтле иҗади яктан актив, ирекле шәхес тәрбияләү, театр сәнгате чаралары ярдәмендә балаларның сәләтләре һәм талантларын ачу, театраль эшчәнлеккә тарту юлы белән, аларның ял сәгатьләрен оештыру өчен шартлар тудыру.

***Программаның бурычлары:***

*Белем бирү:*

- театр сәнгате турында кирәкле белемнәрне булдыру;
- актёрлык күнекмәләре булдыру – партнер белән үзара эшләү, герой образы тудыру, роль өстендә эшләү;
- актёрлык осталыгы өлкәсеннән булган күнегүләр аша игътибарлылыкны ныгытырга, фантазия белән җитәкчелек итәргә, образлы күзаллау булдырырга, психофизик халәтне анализларга өйрәтү;
- уен һәм тренинг күнегүләре аша артык психологик кысырынкылыклардан һәм комплекслардан котылырга ярдәм итү;
- сулыш алу, дикция, интонацияне куюга юнәлтелгән махсус биремнәр һәм күнегүләр ярдәмендә балаларны сөйләм культурасының элементар күнекмәләренә өйрәтү;
- татар теленең хәзерге заман нормаларына нигезләнеп, дөрес әдәби сөйләм, әйтелешне җиңел куллана белергә өйрәтү;

- баланың индивидуаль физик мөмкинлекләреннән чыгып, пластиканың матурлыгын тәэмин итүче практик күнекмәләр булдыру.

*Тәрбияви:*

- җаваплылык, коллективизм, хезмәт сөю, активлык, яхшы күңеллелек, башкаларның иҗатына карата хөрмәт хисе тәрбияләү;
- тәртипнең этик нормаларын, коллективта эшләү һәм уртак кагыйдәләргә буйсыну сәләтен формалаштыру;
- үз эшеңне генә түгел, иптәшләреңнең дә эшләрен тәнкыйти бәяли белергә өйрәтү.

*Акыл сәләтен үстерү:*

- театр сәнгате тарихы һәм теориясе буенча махсус белемнәргә карата кызыксыну уяту;
- иҗади һәм актёрлык сәләтләрен үстерү;
- эстетик кабул итү, сәнгати зәвык, иҗади күзаллауны үстерү;
- ишетү сәләте, игътибарлылык һәм хәтерне үстерү;
- аралашучанлык, тәртиплелек, оештыру сәләте, үз фикеререңне әйтә һәм дәлилли белүне үстерү.

Программада куелган максатларга ирешү өчен түбәндәге төп принципларга таянырга кирәк:

*Фән тармаклары арасындагы интеграция принцибы* – Чиктәш фәннәргә карата кулланыла(әдәбият һәм музыка, әдәбият һәм рәсем, сынлы сәнгать һәм технология, вокал һәм ритмика дәресләре).

*Уңыш принцибы*. Һәр бала теге яки бу эшчәнлек сферасында уңыш тоярга тиеш. Бу исә “Мин – концепция» позитивы формалашуга һәм үзен әйләнә-тирә дөньяның уникаль бер өлеше итеп тануга китерә.

*Индивидуальлек принцибы,* ягъни шәхескә ориентирлашкан юнәлеш.

*Креативлык(иҗади) принцибы.* Иҗади шәхесне бары тик иҗади шартларда гына тәрбияләргә мөмкин.

*Динамика принцибы.* Баланың үзенә кызыклы булган объектларны актив эзләргә һәм үзләштерергә, иҗади эшчәнлектә үз урынын табарга, үзенә ошаган нәрсә белән шөгыльләнергә мөмкинлек бирергә.

*Демократия принцибы.* Конкрет сайланган эшчәнлекнең белемнәрен алуга үз теләге белән ориентирлашу; коллективның уртак эшчәнлеген сайлауны уртага салып тикшерү.

*Һәркемгә туры килү принцибы.* Өйрәтү һәм тәрбияләү, интеллектуаль, физик һәм мораль яктан артык авыр булудан сакланып, яшүсмерләрнең яшьләреннән һәм шәхси мөмкинлекләреннән чыгып төзелә.

*Тормыш белән бәйләнеш принцибы.* Сәнгать , тормышның үзеннән туган һәм аннан аерылгысыз бөйләнештә булучы тере сәнгать буларак карала.

*Күрсәтмәлек принцибы.* Укыту эшчәнлегендә төрледән-төрле иллюстрацияләр, видеокассеталар, дисклар, аудиоязмалар кулланыла.

*Системалылык һәм эзлеклелек принцибы.* Системалылык һәм эзлеклелек дәресләр уздырганда гына түгел, ә бәлки тәрбияләнүчеләрнең мөстәкыйль эшләрендә дә тормышка ашырыла. Бу принцип аз гына вакыт эчендә югары нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирә.

*Коллективизм принцибы* – күмәк иҗади эшләрдә төрле яктан сәләтләрнең үсеше һәм аларны уртак куанычка 1әм файдага бирү ихтыяҗы туа.

Театраль коллективка теләге булган 8-16 яшьлек барлык балалар да әти-әниләренең (яисә аларны алыштыручыларның)  шәхси гаризалары буенча кабул ителә.Төркемнәрдәге балалар саны15тән дә ким булырга тиеш түгел. Коллективта йөрүчеләр составы даими.Балалар коллективтан авыру, яшәү урыннарын үзгәртү яисә әлеге оешмага кызыксынулары бетү сәбәпле китә алалар. Ирекле урыннар булган очракта, балалар коллективка бөтен уку елы дәвамында, әңгәмә нәтиҗәсендә, ә инде икенче һәм аннан да

югарырак уку елы төркеменә тәрбияләнүче бары тик театраль әзерлек, артистизм буенча сынау үткәннән соң гына кабул ителергә мөмкин. Балалар атнага ике тапкыр ике сәгать шөгыльләнәләр. Елга барлыгы 144 сәгать бирелә. Өстәмә тулаем белем бирү тулаем үстерү прогаммасы, каникул вакытларын да үз эченә алып, календарь ел дәвамында тормышка ашырыла. Программаны үтәү барышында мәктәп яны лагерьларында эш оештырыла, күңел ачу, театраль, музыкаль, спорт чаралары үткәрелә.

Программаны тормышка ашыру вакыты - биш ел.

<u>*Укыту этаплары.* </u>Программаны реализацияләү укыту процессының биш баскычында тормышка ашырыла.

*Беренче баскыч* укытуның беренче елына туры килә – бу дәрәҗәнең төп максаты – балаларның гомуми башкару сәләтләрен ачу һәм үстерү, актерлык иҗатына кызыксыну формалаштыру. Беренче ел дәвамында тәрбияләнүчеләр театраль сәнгать өлкәсендә башлангыч белем алалар, үзләре өчен актерлык осталыгының төп материалы булган нәрсәне ачалар, киләсе елларда ныгыячак һәм үсәчәк белем һәм күнекмәләрнең нигезе салына. Беренче елның үзенчәлеге булып, укучыларга киләчәктә алыначак белемнең нигезен тәшкил итәрдәй аерым база бирү тора. Беренче баскычның төп эш формасын театраль уеннар һәм күнегү-импровизацияләр тәшкил итә.

*Икенче баскыч* укытуның икенче елына туры килә – төп максаты – актёрлык осталыгын чыгыш ясау эшчәнлегенә ориентлашып тирәнтен өйрәнү һәм үзләштерү. Икенче ел дәвамында беренче этапта алынган белемнәрне ныгыту һәм киңәйтү эшләре алып барыла, тамашачы алдында актёр чыгышының сәнгатьлелеге һәм көчлелеген камилләштерү дәвам итә. Эш формалары – тренинглар, репетицияләр.

*Өченче баскыч* укытуның өченче елына туры килә – төп максаты – балаларны чыгыш ясарга һәм сәхнәдә “характер” тудырырга ориентлаштыручы иҗади эшчәнлеккә омтылуны ныгыту һәм үстерү. Бу елга бала белем һәм күнекмәләрне тулаем күләмдә ала. Эшчәнлекнең төп формасы булып спектакльләр кую, репетицияләр, тренинглар, уеннар тора.

*Дүртенче баскыч* укытуның дүртенче елына туры килә – төп максаты – балаларны күмәк иҗат җимешенең максатына ирешүгә омтылып, спектакльләрдәге эчке һәм тышкы конфликтларны нечкә тоеп эшләргә өйрәнүне ныгыту һәм үстерү. Дүртенче елда алдагы елларда алган белем һәм күнекмәләрне ныгыту эшләре алып барыла, тамашачы алдында чыгыш ясау бермә-бер арта. Эшчәнлекнең төп формасы булып пьесаларны җентекләп тикшерү, спектакльләр кую, репетицияләр, тренинглар, уеннар тора.

*Бишенче баскыч* укытуның бишенче елына туры килә – төп максаты – сәхнәдә кыю чыгыш ясауны камилләштерү, психологик рольләр тудыруга ориентлаштыручы иҗади эшчәнлеккә омтылуны ныгыту һәм үстерү. Бу елда балалар алда алган белем һәм күнекмәләреннән җиңел файдаланалар, күбрәк чыгыш ясау теләге арта. Төрле күләмдәге бәйгеләрдә теләп катнашалар. Спектакльләрне мөстәкыйль тикшерә алу дәрәҗәсенә күтәреләләр. Эшчәнлекнең төп формасы булып пьесаларны җентекләп тикшерү, спектакльләр кую, репетицияләр, тренинглар, уеннар тора.

Әлеге программа буенча нәтиҗәле эшләү өчен төрледән-төрле формаларны куллану мөһим:

<u>Шөгыльләнүчеләрнең эшчәнлекләрен оештыру формалары. </u>Тулаем коллектив белән эшләү – төп эш формасы.

<u>Занятиеләрне үткәрү формалары:</u> укыту занятиесе; ачык занятие; әңгәмә; театраль куелышларны, видеоязмаларны карау һәм тикшерү; тренинглар; комплекслы күнегүләр; мөстәкыйль эшләр; рольгә керү уены; спектакльләр; репетицияләр; экскурсияләр; культпоходлар.

Укыту-тәрбия процессын оештырганда, түбәндәге <u>укыту методларын</u> куллану мөһим: мәглүмати-рецептив(педагог һәм укучыларның үзара эшчәнлекләренең аңлату-иллюстратив оештыру алымы); аңлату-нәтиҗәлелек (аңлату, әңгәмә, күрсәтү); репродуктив (үрнәк буенча кабатлау); тикшеренү (ассоциацияләр, импровизация,

артистизмлыкка карата күнегүләр); эврестик, өлешчә эзләнү, иҗади ( кечкенә сәхнә күренешләре кую, композицияләр эшләү).

Укыту процессын оештыруда түбәндәге педагогик технологияләр кулланыла: хезмәттәшлек итеп һәм узыштырып укыту; проблемалы укыту; үстереп, алга җибәреп укыту; актив (комплекслы) укыту; социо-уен белән укыту; дифференцияцияле укыту; шәхси- ориентлаштырып укыту.

Өстәмә гомуми белем бирү гомуми акыл үсешен үстерү программасы, каникуляр вакытларны да үз эченә алып, барлык календарь ел дәвамында тормышка ашырыла. Әлеге программаны үтәү барышында мәктәп яны лагерьларында эш оештырыла, күңел ачу-белем бирү спорт мероприятиеләре үткәрелә.

*Көтелгән нәтиҗә:*

Беренче ел ахырына тәрбияләнүчеләр түбәндәгеләрне **белергә тиеш:**

- театр үзенчәлекләрен сәнгать төре буларак, театр сәнгатенең жанрлары һәм төрләре, һөнәрләре турында күзаллау;
- сәнгатьле сөйләмне чыгыш ясау сәнгатенең төре буларак;
- сәхнә грамотасын;
- сәхнәнең төзелеше һәм элементар техник чаралары турында;
- грим сәнгате турында;

***шулай ук:***

- үзенең фантазиясен активлаштыра белергә;
- образлы уйлый белергә;
- дикция күнегүләрен мөстәкыйль үти белергә;
- сәхнә киңлегендә үзен тоя белергә;
- коллективта эшләргә һәм уртак кагыйдәләргә буйсынырга;
- үзенең һәм башка укучыларның сөйләмен анализлый, контрольли һәм бәяли ***белергә тиеш.***

Икенче ел ахырына тәрбияләнүчеләр түбәндәгеләрне **белергә тиеш:**

- этюдның нәрсә булуын, аның структурасын һәм төрләрен;
- сәхнә киңлегендә мезансцена нигезләрен;
- актёрлык тренингының нәрсә булуын һәм аның ни өчен кулланылуын;
- психофизик халәтнең нәрсә икәнен;
- объектны тышкы һәм эчке күзаллау нәрсә булуын;
- сәхнәдә һәм тамашачы залында үзеңне тоту нормаларын;
- сценарий өстендә эшләү нигезләрен;
- сюжетның ниятен;

***шулай ук:***

- грим сала белергә;
- сөйләм аппараты белән белеп эш итәргә;
- этюдларны уйлап чыгарырга, әзерләргә һәм куеп күрсәтергә;
- үзенең һәм иптәшләренең эшләрен анализлый;
- иҗади образлар тудыра ***белергә тиеш.***

Өченче ел ахырына тәрбияләнүчеләр түбәндәгеләрне **белергә тиеш:**

- әсәр сюжеты тууы турында;
- сәнгатьлелек чараларының нәрсә булуын;
- сюжетның төп өлеше буларак фрагмент турында;
- драматик әсәрдәге конфликт турында;
- башкарылучы формуланы: баштагы вакыйга, конфликтлы ситуация, финал;
- актер халәтенең эчке монологы турында;

***шулай ук:***

- сәхнә характерын белдерер өчен сәнгатьлелек чаралары куллана белергә;

- әсәрне фрагментларга бүләргә һәм фрагментлап тикшерә алырга;
- әсәрдәге төп фикерне ачыклый белергә, аның сюжетын формалаштырырга;
- (әсәрдәге холыклары буенча) логик яктан сайланган геройларны бер сюжет линиясенә яраклаштыра белергә;
- аудитория һәм сыйныфташлары белән җиңел аралаша белергә;
- оппонентларның арасында үз фикерен белдерә белергә;
- эшләнгән эшләрнең эзлеклелеген анализлый белергә;
- роль өстендә мөстәкыйль эшли , спектакльдән спектакльгә үз ролен башкаруда төзәтмәләр кертә белергә;
- башкаруда текстны тәгаен үти белергә;
- тамашачыларның реакцияләрен культуралы итеп кабул итә белергә ***тиеш.***

<u>Дүртенче ел ахырына</u> тәрбияләнүчеләр түбәндәгеләрне **белергә тиеш:**

- татар театр тарихын яхшы күзаллый;
- татар театрының рус һәм башка милли театрлардан аерып торучы үзенчәлекләрен күзаллый;
- сәхнә әсәренең темасын, югары бурычын, идеясын аерып күрсәтә белергә;
- партнёр белән эшләүнең төп кагыйдәләрен белергә;
- киләсе чыгышның структурасын һәм эчтәлеген ачык белергә;
- әсәр текстын тикшергәндә логик басым, синтагма басымы, паузаларны дөрес билгели;

***шулай ук:***

- һәр сюжеттагы конфликтны җиңел күрсәтә белергә;
- үзе башкарган геройны яклый алырга;
- рольләрен башкарганда ясаган хаталарын мөстәкыйль тоемлый белергә;
- әсәрдәге эчке һәм тышкы конфликтларны тоя белергә ***тиеш.***

Бишенче ел ахырына тәрбияләнүчеләр түбәндәгеләрне **белергә тиеш:**

- татар театры белән беррәттән, рус һәм чит ил театрлары тарихын да яхшы күзалларга;
- әсәрләрне мөстәкыйль тикшерә белергә, әсәр тикшерүдә иптәшләре ясаган хатаны төзәтә алырга;
- репетицияләр вакытында башка нәрсәләргә игътибарын юнәлтмичә, интенсив эшли белергә;
- психологик рольләр башкаруда кирәкле психофизик халәт турында белергә;

***шулай ук:***

- драматик әсәрне мөстәкыйль тикшерә белергә;
- катлаулы грим сала белергә;
- башкарган күмәк эшкә режиссёр күзлегеннән карый, бәяли белергә;
- чыгыш ясарга мөстәкыйль әзерләнә алырга ***тиеш.***

Әлеге программа буенча барлык этапларны да үткән укучылар театр сәнгате, теоретик белемнәрһәм практик күнекмәләр турында гомуми мәгълүматлар алырга тиешләр:

- “этюд”, “вакыйга”, “конфликт”, “образ”, “пауза”, “күренеш” һәм башка шундый театраль термин һәм төшенчәләрне куллану;
- геройның тышкы кыяфәте өстендә эшләгәндә алынган практик күнекмәләрдән файдалану – грим, костюм, причёскадан;
- мөһим актёрлык күнекмәләреннән файдалану: партнёр белән үзара җиңел эш итү, тәкъдим ителгән шартларда эшләү, игътибарны юнәлтү, импровизацияләү, эмоциональ хәтерне “кабызу”, тамашачы белән аралашу;
- пластик сәнгатьлелек һәм сәнгатьле сөйләм өчен кирәкле мөһим күнекмәләрне үзләштерү;

- уртак эш өстендә эшләгәндә (декорацияләр бизәгәндә, фонограммалар яздырганда) үзеңнең шәхси сәләтләреңне актив күрсәтү.

Ә иң мөһиме, һәрдаим рухи камиллеккә омтылу, үзеңнең мәдәни күз күремеңне, белемеңне киңәйтү.

Нәтиҗәләр чыгару һәм контроль формалары:

Әлеге программаны тулаем тормышка ашыру өчен төрле контроль чаралары кулланыла:

- агымдагы – дәресләр вакытында баланың эшчәнлеге артыннан күзәтү юлы белән тормышка ашырыла;
- ара-ара – өстәмә белем бирү учреждениеләрендә уздырылучы тестлар, бәйрәмнәр, бәйгеләр;
- йомгаклау – ачык занятиеләр, спектакль, фестивальләр.

***Укытуның 1нче елы***

| № п/п | Наименование раздела, темы | Количество часов | | | Формы промежуточной аттестации/ контроля |
|---|---|---|---|---|---|
| | | теория | прак тика | всего | |
| 1. | Кереш дәрес | 1 | 1 | 2 | |
| 2. | Театр тарихы | 1 | 3 | 4 | |
| 3. | Сөйләм культурасы һәм техникасы | 4 | 16 | 20 | |
| 4. | Сәхнә хәрәкәте | 2 | 18 | 20 | |
| 5. | Актерлык грамотасы | 4 | 76 | 80 | |
| 6. | Этика һәм этикет | 2 | 2 | 4 | |
| 7. | Театр культурасы нигезләре | 3 | 1 | 4 | |
| 8. | Тәрбияви- укыту характе-рындагы мероприятиеләр | 1 | 7 | 8 | |
| 9. | Йомгаклау дәресләре | - | 2 | 2 | |
| | Итого | 18 | 126 | 144 | |

***Беренче уку елы программасының эчтәлеге.***

**Тема 1. Кереш дәрес -2 сәг.**

*Теоретик дәрес:* Балалар белән танышу. Укытуның максатлары һәм бурычлары.

Балаларны студиянең эшчәнлеге белән таныштыру, кызыксыну уяту, театр "чирен йоктыру".

Кереш дәрес балалар белән танышу, аларны студиянең программасы белән таныштыру максатыннан чыгып үткәрелә.Театр дөньясына беренче адымнар ясала.

Балалар студиядә үткәрелүче дәресләрдә үз-үзеңне тоту һәм куркынычсызлык кагыйдәләре белән танышалар.

*Практик дәрес:* Спектакль видеоязмалары, иҗади эшләр карап уздырыла.

**Тема 2. Театр тарихы -4 сәг.**

*Теоретик дәрес:*Сәнгать төре буларак театр. Театр сәнгатенең жанр һәм төрләре: драма, сатира һәм юмор театры, музыкаль театр(опреа, балет, оперетта, мюзикл), курчак театры.

Театр сәнгатенең беренче карлыгачлары скоморохлар – Русьнең беренче профессионал актерлары.

Татар театры туу.

*Практик дәрес:* Курчак театрына сәяхәт.

**Тема 3. Сөйләм культурасы һәм техникасы -20 сәг.**

*Теоретик дәрес:* Тавыш өстендә практик эшнең нигезләре. Сөйләм аппаратының анатомия, физиология, гигиенасы. Әдәби әйтелеш.

Дикция. Артикуляцион гимнастика һәм аның әһәмияте.

Фразаларны сәхнәчә “төзү”, ясау нигезләре (сөйләм логикасы). Фраза турында төшенчә. Фразаның табигый төзелеше. Гади һәм катлаулы фраза. Фразаның аңлатмасы һәм нигезләре. Басларда һәм югарыда аңлатмалар.

Сүзләр йогынтысының классификациясе. Әдәби әсәрнең тексты һәм подтексты. Яңгыравык тавыш белән теге яки бу картинаны ясау мөмкинлеге.

*Практик дәрес:* Сулыш алу усешенә һәм сөйләм аппаратының иреклелегенә , дөрес артикуляция, ачык дикция, логика һәм орфоэпиягә юнәлтелгән уен һәм күнегүләр.

Авазлар туугa караган күнегүләр: “Бамбук”, “Фонарь” һ.б.

Артикуляцион гимнастика: иреннәргә, телгә күнегүләр.

Тавышка күнегүләр һ.б.

**Тема 4. Сәхнә хәрәкәте -20 сәг.**

*Теоретик дәрес:* Пластик сәнгатьлелек. Иркенлек һәм сәнгатьлелекнең үсеше. Акробатика нигезләре, тигезлек (равновесие) белән эш, предметлар белән эш. Куркынычсызлык кагыйдәләре.

*Практик дәрес:* Баланың хәрәкәт итү сәләтен үстерү, тән хәрәкәтенең пластик сәнгатьлелеге.

Сәхнә ягылулары: алга бөгелеп егылу, артка аркага егылу.

Психофизик тренинг, этюдларга әзерләнү. Координация үсеше. Гәүдә һәм атлап йөрешне камилләштерү.

Сәхнә этюдын эшкәртү: “Мөрәҗәгать итү” ( “Танышу”, “ Теләк”, “Көзге”)

Предметсыз этюд (энәгә җеп кертү, чемоданга әйберләрне җыю, карандаш очлау һ.б.)

Сәхнә этюды: “Скульптура”. Парлы этюдлар: “Реклама”, “Каршылык”.

Төркемле этюдлар: “Бик зур картина”, “Пейзаж” һ.б.

**Тема 5. Актерлык грамотасы -80 сәг.**

*Теоретик дәрес:* Театрда сәнгатьлелек чараларының күптөрлелеге. Сәхнә игътибарлылыгы. Игътибарлылык төрләре.

*Практик дәрес:* Игътибарлылыкка тренинглар: “Күренмәс җеп”, “Алкышны тот” һ.б.

*Теоретик дәрес:* Театр сәнгатенең үзәге – актерның башкару сәнгате. Актерның үз-үзенең тотышын үзгәртүе ярдәмендә урын, вакыт, ситуация, партнерларын “башкага әверелдерү”, үзгәртә алу мөмкинлекләре.

*Практик дәрес:* Эш-хәрәкәтләрнең коллектив килешүчәнлегенә ( бер үк вакытта, берсе артыннан берсе, үз вакытында) корылган, эш-хәрәкәт ярдәмендә бирелгән предметларның башка нәрсәләргә әверелүенә ( индивидуаль, ярдәмчеләр белән) юнәлтелгән күнегүләр.

*Теоретик дәрес:* Сүзсез һәм сүзле эш-хәрәкәтләр – уйлап чыгару шартларында тәртипнең органиклыгына караган таләпләрне үстерү. Сүзле эш-хәрәкәт. Сөйләмнең психофизик сәнгатьлелеге. Подтекст буларак сүзләрнең йогынтысы, тәэсире. Бирелгән сүзле эш-хәрәкәтләр чылбырын этюд аркылы яклау.

*Практик дәрес:* Этюд, күнегләр, тренинглар башкару; “Мин бүген – ул...” күнегүе, мәкальләргә, канатлы сүзләргә, сюжетлы шигырьләргә этюдлар; картиналар – ялгыз, парлы, төркемле, сүзсез һәм текстны бик аз күләмдә кулланып.

*Теоретик дәрес:* Спектакльнең нигезе – пьеса. Пьесаның композицион төзелеш үзенчәлекләре: аның экспозициясе, төен, кульминация һәм чишелеше. Пьесадагы вакыт. Спектакльдә катнашучылар – персонажлар.

*Практик дәрес:* Балалар әкият-спектакленең сценарие белән танышу ( пьеса, аның темасы, идеясы, куелыш принциплары буенча әңгәмә) .

Укучыларның теләкләре буенча рольләрне бүлеп бирү һәм аларның һәрберсенең дә үз роленә туры килүе (кыяфәтләре, дикцияләре һәм башка яктан). Әкиятне рольләргә бүлеп сәнгатьле уку.

Тәкъдим ителгән шартлар, хәл, әкияттәге һәр персонажның үз-үзен тотышын уртага салып тикшерү. Аерым эпизодларга репетиция ясау.

Әкият күрсәтү.

**Тема 6. Этика һәм этикет -4 сәг.**

*Теоретик дәрес:* Этиканың кешенең гомум культурасы белән бәйләнеше.

*Практик дәрес:* “Хөрмәт” темасы турында( кешенең кешегә, табигатькә, җиргә, Ватанга, балачакка, картлыкка, анага, икмәккә, белемгә һәм үз-үзенә карата хөрмәте) әңгәмә.

**Тема 7. Театр культурасы нигезләре -4 сәг.**

*Теоретик дәрес:*Театр терминологиясе белән таныштыру. Театр сәнгатенең төрләре. Сәхнә һәм тамашачы залының төзелеше. Театраль һөнәрләр. Театр структурасы, аның төп һөнәрләре - актер, режиссёр, сценарист, рәссам, гримёр – белән таныштыру.

Сәнгатьлелеккә ирешүнең бер чарасы буларак грим: гадәти, эстрада, характерлы, абстракт. Грим салу юллары.

Образ һәм характер турындагы күзаллауга тәэсир итүче төп элементларның берсе – костюм. “Конкретлаштырылган” һәм “универсал” костюм. Төсе, фактурасы.

*Практик дәрес:* Театр һөнәре элементлары белән танышуга иҗади биремнәр: афишалар, декорациягә эскизлар һәм костюмнар иҗат итү.

Грим салу алымнары. Сайланган пьеса геройлары өчен грим эскизлары тудыру. Шөгыльләнүчеләрнең бер-берсенә грим салуы.

Сайланган пьеса өчен костюм эскизлары ясау.

Театрга экскурсия.

**Тема 8. Тәрбияви- укыту характерындагы мероприятиеләр -8 сәг.**

*Теоретик дәрес:* ял мероприятиеләрен оештыру һәм уздыру формасы белән таныштыру, сценарийлар эшләү.

*Практик дәрес:* Берләшмә эчендәге ял мероприятиеләрен әзерләүдә катнашу.

**Тема 9. Йомгаклау дәресләре -2 сәг.**

*Практик дәрес:* Йомгаклап чыгыш ясау, тикшерү.

**Укыту-тематик план 2 нче ел**

| № п/п | Наименование раздела, темы | Количество часов | | | Формы промежуточной аттестации/ контроля |
|---|---|---|---|---|---|
| | | теория | практика | всего | |
| 1. | Кереш дәрес | 1 | 1 | 2 | |
| 2. | Театр тарихы | 1 | 3 | 4 | |
| 3. | Сөйләм культурасы һәм техникасы | 4 | 16 | 20 | |
| 4. | Сәхнә хәрәкәте | 2 | 18 | 20 | |
| 5. | Актерлык грамотасы | 4 | 76 | 80 | |
| 6. | Этика һәм этикет | 2 | 2 | 4 | |
| 7. | Театр культурасы нигезләре | 3 | 1 | 4 | |
| 8. | Тәрбияви- укыту характе-рындагы мероприятиеләр | 1 | 7 | 8 | |
| 9. | Йомгаклау дәресләре | - | 2 | 2 | |
| | Итого | 18 | 126 | 144 | |

***Икенче уку елы программасының эчтәлеге.***

**Тема 1. Кереш дәрес -2 сәг**

*Теоретик дәрес:* Укытуның максат һәм бурычлары. Курс белән танышу. Икенче шөгыльләнү елында иҗади үсеш перспективасы. Занятиеләрдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен кабатлау. Куркынычсызлык кагыйдәләре буенча инструктаж уздыру.

*Практик дәрес:* Белем бәйрәмендә катнашу. Театраль берләшмәнең иҗади остаханә почмагын әзерләү.

**Тема 2. Театр тарихы -4 сәг**

*Теоретик дәрес:* Казан театрларының тарих битләре. Татар яшь тамашачылар театры, Муса Җәлил исемендәге татар академия дәүләт опера һәм балет театры, В.М. Качалов исемендәге Казан академия рус драма театы, Татар Дәүләт "Әкият" курчак театры, Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театры, К.Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм академия театры.

*Практик дәрес:* Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театрына сәяхәт.

**Тема 3. Сөйләм культурасы һәм техникасы -20 сәг**

*Теоретик дәрес:* Текстны үзләштерүнең соңгы этабы буларак, кычкырып уку. Тере сөйләмдә сүзләр тәэсире һәм аларны сөйләм эшендә куллану.

Сөйләү, аралашу барышында интонация кануннары. Гади һәм катлаулы җөмләләр. Сөйләм темпы. Сөйләм ритмы. Сөйләм логикасы(мәгънәсе).

Сәнгати алымнарның күптөрлелеге. Яңгыравык тавыш белән теге яки бу картинаны "ясау" мөмкинлеге. Ясалучы картинаның әдәби әсәр жанры белән бәйләнеше. Лирика башкаруның үзенчәлекләре.

*Практик дәрес:* Укыганда дөрес сулыш алу күнекмәләрен, сөйләмтавыш аппараты(тавышның диапозоны, аның көче һәм хәрәкәтчәнлеге) белән аңлы рәвештә җитәкчелек итүне эшкәртү.

Аваз тууга карата күнегүләр. Сүзнең тәэсиренә максатчан юнәлдерелгән этюд һәм күнегүләр.

Образлы бәйләнешле сөйләмне үстерүче сүзләр белән уеннар. ( "Уйланылган нәрсәне нәрсәгә ошатасыз?", "Абсурд театры", "Сибел!", "Гаепләү һәм яклау")

"Күпйөзле сүзләр" темасына кечкенә хикәя төзү.

Күкрәк резонаторын үстерүче күнегүләр өстендә эш( "Паровоз", "Урам буйлап атлар килә", "Шәм", тизәйткечләр, мәкальләр).

Фразаны сәхнәви "ясау" нигезләре(Сөйләм логикасы). Фраза турында төшенчә. Фразаның табигый төзелеше. Яңгыравык тавыш белән теге яки бу картинаны "ясау" мөмкинлеге. Ясалучы картинаның әдәби әсәр жанры белән бәйләнеше. Лирика башкаруның үзенчәлекләре.

Әсәрне башкаруга(татар, рус прозасы һәм поэзиясе материалында) мөстәкыйль әзерләнү.

**Тема 4. Сәхнә хәрәкәте -20 сәг.**

*Теоретик дәрес:* Пантомимо сәнгате.

*Практик дәрес:* Хәрәкәтләрнең ритмлылыгын күнектерү.

Музыкаль пластик импровизацияләр. Пантомимо куюы.

Пантомимик этюдлар"Берсе эшли, икенчесе комаучаулый", "Образдагы хәрәкәтләр", "Көтү", "Диалог".

Гәүдә тотышын һәм йөрешне камилләштерүче күнегүләр.

"Картина галериясе" пантомимик этюды. "Терелүче картина" пантомимик этюдын төзү.

**Тема 5. Актерлык грамотасы -80 сәг.**

*Теоретик дәрес:* Спектакльдәге мезансценалар. Куелган мезансценаларны башкару төгәллеге һәм импровизация.

Үзеңнең эш-хәрәкәт логикасын персонажның эш-хәрәкәт логикасына әверелдерү алымнары һәм әһәмияте. Сайланган өзектәге бер үк катнашучының үз-үзен тотыш логикаларының төрлелеге. Статистик башкарылуны( яисә, Станиславскийча, "хисләрдә коенуны") җиңеп чыгуга ярдәм итүче актерлык сәнгате чаралары турындагы беренчел күзаллау.

Эш-хәрәкәт техникасын үзләштерүне активлаштыру чарасы буларак, һәр шөгыльләнүченең берничә роле өстендә параллель эшкәртү эше алып бару. Бирелгән сүзле эш-хәрәкәтнең чылбырын этюд аркылы яклау. Парлы этюд ниятенең тәэсир итүче характеры турындагы күзаллау барлыкка килү.

Пьесаның композицион төзелеш үзенчәлекләре:  аның экспозициясе, төенләнеше, кульминация һәм чишелеше. Пьесадагы вакыт. Спектакльдә катнашучылар – персонажлар.

Персонажга сөйләми характеристика. Сөйләмдә һәм сөйләмнән тыш үз-үзен тотышы. Монолог һәм диалог.

*Практик дәрес:*  Мезансценаның һәр сәхнә күренеше бурычы белән бәйләнеш күнекмәләре һәм осталыкларын эшкәртү. Төркемдәге барлык балаларның бер роль( (бер өзек) өстендә эшләре. Бер үк өзекне төрле составлар  башкаруында коллектив күрсәтү. Эшләү характерының аерымлыкларын ачыклау. Эш-хәрәкәтнең коллектив килешүчәнлегенә күнегүләр(Бер үк вакытта, берсе артыннан берсе, үз вакытында). Тәрбияләүче ситуацияләр(“ Әгәр мин берүзем уйнасам, нәрсә булыр...” Бирелгән предметның эш-хәрәкәт ярдәмендә башка нәрсәгә әверелүе( индивидуаль, ярдәмчеләр белән).

Мәкаль, канатлы сүз, әйтем, сюжетлы шигырьләр, картиналарга – ялгыз, парлы, төркемле, сүзле, сүзсез һәм текстны минималь кулланып ясалган этюдлар.

Сайланган пьеса өстендә эш, сюжет турында уйлану, Эш-хәрәкәт үсеше барышында борылыш, үзгәреш моментлары булып торучы төп вакыйгаларны  бүлеп чыгару. Төп конфликт аша ачыкланучы пьесаның төп темасы һәм автор идеясын билгеләү. Спектакльнең жанрын ачыклау.

Пьесаны уку, тикшерү, аның тема, идеясын ачыклау.Спектакльдә әйтелергә теләгән фикер турында гомуми сөйләшү. Күренеш, эпизодларны берләштерү; декорацияләр, реквизит, бутофорияләр белән репетицияләр; костюмнарда  репетицияләр; музыкаль һәм ут бизәләше белән репетицияләр; барлык сәнгати чараларны берләштерүче репетицияләр. Генераль репетиция. Спектакль күрсәтү.

**Тема 6. Этика һәм этикет  -4 сәг.**

*Теоретик дәрес:* Кеше образының, аның мөлаемлылыгының бер мөһим өлеше булып торучы сөйләм культурасы. Сөйләм этикеты. Лексика, интонацияне сайлау,  сөйләшү, сөйләм хаталары, сөйләм йомшаклыгы һәм катылыгы.

Үз-үзеңне тоту һәм  аралашу нормалары: урамда, транспортта үз-үзеңне тоту; телефоннан сөйләшү; кибеттә үз-үзеңне тоту. Шөгыльләнүчеләрнең мисаллары.

“Минем шәҗәрәм” темасына әңгәмә.

*Практик дәрес:*

“Изге хәтер” иҗади эше. Иҗат эшләрен анализлау.

“Сорау һәм җавапларда этикет” гәҗите чыгару. (Материаллар җыю, тикшерү, бурычларны бүлеп бирү.

**Тема 7. Театр культурасы нигезләре -4 сәг.**

*Теоретик дәрес:* Грим ярдәмендә сәхнә образын чагылдыру.Сәнгатьлелеккә ирешүнең бер чарасы буларак грим: гадәти, эстрада, характерлы, абстракт. Грим салу алымнары.

Образ һәм характер турында күзаллауга тәэсир итүче төп элементларның берсе буларак костюм. “Конкретлаштырылган” һәм “универсаль” костюм. Төсе, фактурасы.

*Практик дәрес:*  Грим салу алымнары. Сайланган пьеса геройлары өчен грим эскизлары тудыру. Шөгыльләнүчеләрнең бер-берсенә грим салуы.

Сайланган пьеса өчен костюм эскизлары тудыру.

**Тема 8. Тәрбияви- укыту характерындагы мероприятиеләр  - 8 сәг.**

*Теоретик дәрес:* Ял итү мероприятиеләрен оештыру һәм уздыру формалары белән таныштыру, сценарийларны эшкәртү.

*Практик дәрес:*  Берләшмә эчендә һәм мәктәптә үткәрелгән  ял итү мероприятиеләренә әзерләнүдә катнашу.

**Тема 9. Йомгаклау дәресләре  -2 сәг.**

*Теоретик дәрес:* Бер ел эчендә өйрәтү (укыту) программасы бүлекләре буенча викторина.

*Практик дәрес:* Имтихан-чыгыш: коллектив килешүчәнлеккә күнегүләр; предметның, поза, ситуация, мизансценаның әверелүе һәм аны яклау; тәкъдим ителгән төрле шартларда бирелгән сүзсез эш-хәрәкәт элементларын яклауга этюдлар.

**Укыту-тематик план 3 нче ел**

| № п/п | Наименование раздела, темы | Количество часов | | | Формы промежу-точной аттеста-ции/ контроля |
|---|---|---|---|---|---|
| | | теория | прак тика | всего | |
| 1. | Кереш дәрес | 1 | 1 | 2 | |
| 2. | Театр тарихы | 1 | 3 | 4 | |
| 3. | Сөйләм культурасы һәм техникасы | 4 | 16 | 20 | |
| 4. | Сәхнә хәрәкәте | 2 | 18 | 20 | |
| 5. | Актерлык грамотасы | 4 | 76 | 80 | |
| 6. | Этика һәм этикет | 2 | 2 | 4 | |
| 7. | Театр культурасы нигезләре | 3 | 1 | 4 | |
| 8. | Тәрбияви- укыту характе-рындагы мероприятиеләр | 1 | 7 | 8 | |
| 9. | Йомгаклау дәресләре | - | 2 | 2 | |
| | Итого | 18 | 126 | 144 | |

***Өченче уку елы программасының эчтәлеге***

**Тема 1. Кереш дәрес -2 сәг.**

*Теоретик дәрес:* Укытуның бурыч һәм максатлары. Курс белән таныштыру. Өченче шөгыльләнү елында иҗади үсеш перспективасы. Занятиеләрдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен кабатлау. Куркынычсызлык кагыйдәләре буенча инструктаж уздыру.

*Практик дәрес:* Анкета: “Берләшмә эше буенча сезнең тәкъдимнәрегез”.

**Тема 2. Театр тарихы -4 сәг.**

*Теоретик дәрес:* Казан театрларының танылган әһелләре Г. Камал, В.И.Качалов, К. Тинчурин, М.Х. Сәлимҗановларның тормыш һәм иҗат юллары белән таныштыру.

*Практик дәрес:* Бирелгән темалар буенча шөгыльләнүчеләрнең реферат эшләре.

**Тема 3. Сөйләм культурасы һәм техникасы -20 сәг.**

*Теоретик дәрес:*Хикәя һәм драматик текст. Персонажга сөйләми характеристика. Сөйләмдә һәм сөйләмнән тыш үз-үзен тотышы. Монолог һәм диалог.

Аралашу үзенчәлекләрендә кеше индивидуальлелегенең күренүе. Шәхесара аралашу логикасы белән танышу. Сәхнәви сәнгатьлелекнең шарты буларак, шәхесара аралашудагы көрәш.

Чыгыш ясауның индивидуаль формаларының күптөрлелеге. Концертта сөйләүче номеры. Мелодекламация. Әдәби композиция һәм монтаж. “Бер актер театры”.

*Практик дәрес:* Сөйләү тавышының көчен һәм очышын үстерүче күнегүләр өстендә эш.

Укыганда дөрес сулыш алу күнекмәләрен һәм сөйләмтавыш аппараты(тавыш диапозоны, аның көче һәм хәрәкәтчәнлеге) белән аңлы рәвештә җитәкчелек итүне эшкәртү. Аваз тууга карата күнегүләр.

**Тема 4. Сәхнә хәрәкәте -20 сәг.**

*Теоретик дәрес:*Пантомимо сәнгате.

*Практик дәрес:* Пантомимик этюд- көләгә. Хәрәкәтләрнең координациясе. Хайваннарның үз-үзләрен тотуларына имитация. Күзәтүчәнлеккә этюд.

**Тема 5. Актерлык грамотасы -80 сәг.**

*Теоретик дәрес:* Партнер белән үзара эшләүнең корылышы логикасы үзенчәлекләрендә кешене характерлаучы төп үзенчәлекләрнең килеп чыгышы (аралашу

параметрлары). Актер иҗатында техниканың камилләшүе өстендә һәрдаим эшләүнең әһәмияте.

*Практик дәрес:* Эш-хәрәкәтнең коллектив килешүчәнлегенә күнегүләр(Бер үк вакытта, берсе артыннан берсе, үз вакытында). Шәхесара аралашу параметрларының берсенең сәнгати бирелешенә этюдлар: көчләр, кызыксыну, инициативлык, претенциозлык нисбәте яисә эшкә йотылу. Мәкаль, канатлы сүз, әйтем, сюжетлы шигырьләр, картиналарга – ялгыз, парлы, төркемле, сүзле, сүзсез һәм текстны минималь кулланып ясалган этюдлар.

*Теоретик дәрес:* Пьесаның композицион төзелеш үзенчәлекләре: аның экспозициясе, төенләнеше, кульминация һәм чишелеше. Пьесадагы вакыт. Спектакльдә катнашучылар – персонажлар.

*Практик дәрес:* Сайланган пьеса өстендә эш, сюжет турында уйлану. Эш-хәрәкәт үсеше барышында борылыш, үзгәреш моментлары булып торучы төп вакыйгаларны бүлеп чыгару. Төп конфликт аша ачыкланучы пьесаның төп темасы һәм автор идеясын билгеләү. Спектакльнең жанрын ачыклау.

Пьесаны уку, тикшерү, аның тема, идеясын ачыклау.Спектакльдә әйтелергә теләгән фикер турында гомуми сөйләшү. Күренеш, эпизодларны берләштерү; декорацияләр, реквизит, бутофорияләр белән репетицияләр; костюмнарда репетицияләр; музыкаль һәм ут бизәләше белән репетицияләр; барлык сәнгати чараларны берләштерүче репетицияләр. Генераль репетиция.

Спектакль күрсәтү.

**Тема 6. Этика һәм этикет -4 сәг.**

*Теоретик дәрес:* Әңгәмә: “Мин дөнья…мин дөнья эчендә...”(Дуслык). Ситуацияләр чишелеше.

*Практик дәрес:* “Эмоция үзенчәлекләре”нә тест үткәрү. Тестны анализлау. “Иҗат ит, уйлап чыгар, чамалап кара!” гәҗите чыгару(материал җыю, әңгәмә үткәрү, бурычларны бүлешү).

**Тема 7. Театр культурасы нигезләре -4 сәг.**

*Теоретик дәрес:* Грим ярдәмендә сәхнә образын чагылдыру.Сәнгатьлелеккә ирешүнең бер чарасы буларак грим: гадәти, эстрада, характерлы, абстракт. Грим салу алымнары.

*Практик дәрес:* Грим салу алымнары. Сайланган пьеса геройлары өчен грим эскизлары тудыру. Шөгыльләнүчеләрнең бер-берсенә грим салуы.

*Теоретик дәрес:* Образ һәм характер турында күзаллауга тәэсир итүче төп элементларның берсе буларак костюм. “Конкретлаштырылган” һәм “универсаль” костюм. Төсе, фактурасы.

*Практик дәрес:* Сайланган пьеса өчен костюм эскизлары тудыру.

**Тема 8. Тәрбияви- укыту характерындагы мероприятиеләр - 8 сәг.**

*Теоретик дәрес:* Ял итү мероприятиеләрен оештыру һәм уздыру формалары белән таныштыру. Тематик планлаштыру, сценарийларны эшкәртү.

*Практик дәрес:* Берләшмә эчендә һәм мәктәптә үткәрелгән ял итү мероприятиеләренә әзерләнүдә катнашу. Хаталарны тикшерү.

Экскурсия, очрашу, культпоходлар.

**Тема 9. Йомгаклау дәресләре -2 сәг.**

*Теоретик дәрес:* Ел дәвамында өйрәтү (укыту) программасы бүлекләре буенча викторина.

*Практик дәрес:* Имтихан-чыгыш: коллектив килешүчәнлеккә күнегүләр; предметның, поза, ситуация, мизансценаның әверелүе һәм аны яклау; тәкъдим ителгән төрле шартларда бирелгән сүзсез эш-хәрәкәт элементларын яклауга этюдлар.

## Укыту-тематик план 4 нче ел

| № п/п | Наименование раздела, темы | Количество часов | | | Формы промежуточной аттестации/ контроля |
|---|---|---|---|---|---|
| | | теория | прак тика | всего | |
| 1. | Кереш дәрес | 1 | 1 | 2 | |
| 2. | Театр тарихы | 1 | 3 | 4 | |
| 3. | Сөйләм культурасы һәм техникасы | 4 | 16 | 20 | |
| 4. | Сәхнә хәрәкәте | 2 | 18 | 20 | |
| 5. | Актерлык грамотасы | 4 | 76 | 80 | |
| 6. | Этика һәм этикет | 2 | 2 | 4 | |
| 7. | Театр культурасы нигезләре | 3 | 1 | 4 | |
| 8. | Тәрбияви- укыту характе-рындагы мероприятиеләр | - | 8 | 8 | |
| 9. | Йомгаклау дәресләре | | 2 | 2 | |
| | Итого | 17 | 127 | 144 | |

***Дүртенче уку елы программасының эчтәлеге.***

**Тема 1. Кереш дәрес -2 сәг.**

*Теоретик дәрес:* Укытуның бурыч һәм максатлары. Курс белән таныштыру. Дүртенче шөгыльләнү елында иҗади үсеш перспективасы. Занятиеләрдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен кабатлау. Куркынычсызлык кагыйдәләре буенча инструктаж уздыру.

*Практик дәрес:* Белем бәйрәмендә катнашу. Театраль берләшмәнең иҗади остаханә почмагын тулыландыру.

**Тема 2. Театр тарихы -4 сәг**

*Теоретик дәрес:* Татар театры тарихында хатын-кыз артистлар.

*Теоретик дәрес:* Татар театрында беренче хатын-кыз артист - Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяның тормыш һәм иҗат юлы белән таныштыру.

*Практик дәрес:* “Гөлҗамал” спектаклен язмада карап, әңгәмә үткәрү.

*Теоретик дәрес:* Рус театр тарихында хатын-кыз артистларның тоткан урыны.

*Практик дәрес:* Бирелгән тема буенча шөгыльләнүчеләрнең реферат эшләре.

**Тема 3. Сөйләм культурасы һәм техникасы -20 сәг.**

*Теоретик дәрес:* Сөйләм теле - роль тудыруда иң мөһим чараларның берсе буларак, тагы да камилләштерелә.

Дикция, сулыш алу, тавыш, орфоэпия, сөйләм теленең логик-интонацион закончалыкларына зур игътибар бирелә.

*Практик дәрес:* Сулыш алу усешенә һәм сөйләм аппаратының иреклелегенә , дөрес артикуляция, ачык дикция, логика һәм орфоэпиягә юнәлтелгән уен һәм күнегүләр.

*Теоретик дәрес:* Комедия әсәрләреннән монологлар. Әсәрнең жанрын тоеп эш итү.

*Практик дәрес:* Шөгыльләнүчеләрнең үзләре чыгыш ясаучы әсәрләрен тикшерүдә мөстәкыйль эшләре.

**Тема 4. Сәхнә хәрәкәте -20 сәг.**

*Теоретик дәрес:* Сөйләми хәрәкәт һәм вокаллы хәрәкәти координацияләр( сөйләм һәм хәрәкәтне бер үк яисә башкару дәвамында алышынып торучы эш-хәрәкәт темп-ритмында берләштерү осталыгы).

*Практик дәрес:* Хәрәкәтләрнең координациясе.

*Теоретик дәрес:* Хәрәкәтләрнең өзлеклелеге һәм өзлексезлеге. Хәрәкәтләрнең характеры.

*Практик дәрес:* Күзәтүчәнлеккә этюдлар.

**Тема 5. Актерлык грамотасы -80 сәг.**

*Теоретик дәрес:* Актерлык иҗатының нигезен тәшкил итүче буларак, тулысынча әверелү принцибын тормышка ашыру.

Бер-берсе белән шартлы рәвештә генә аерылып торучы тышкы һәм эчке әверелү принциплары яшәп килә. Бу бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә торучы катлаулы иҗат процессының ике ягын тәшкил итә. Әверелү процессында эш-хәрәкәт, уй һәм хис аерылгысыз бердәмлектә тора. Актёрга грим, костюм( ә кайбер вакытта маска) ярдәмгә килә, ул сурәтләгән геройның үз-үзен тотыш манерасын, төс-кыяфәтен театраль шартлылыкка туры килерлек итеп тасвирлау өчен, актер интонация, жест, мимика һәм атлап йөрешне үзендә булдыра. Ләкин чын әверелү сәхнәдә персонажның тышкы кыяфәтен генә җиткерүдән гыйбарәт түгел, ә бәлки, үз героеның эчке дөньясын ачып салу, аның борчу-уйлары белән яшәү күпкә мөһимрәк икәнен шөгыльләнүчеләргә кат-кат җиткерү мөһим .

*Практик дәрес:* Шөгыльләнүчеләр мөстәкыйль рәвештә үзләре уйныйсы геройларның эчке һәм тышкы якларына характеристика ясыйлар.

*Теоретик дәрес:* Пьесаның композицион төзелеш үзенчәлекләре: аның экспозициясе, төенләнеше, кульминация һәм чишелеше. Пьесадагы вакыт. Спектакльдә катнашучылар – персонажлар.

*Практик дәрес:* Сайланган пьеса өстендә эш, сюжет турында уйлану, Эш-хәрәкәт үсеше барышында борылыш, үзгәреш моментлары булып торучы төп вакыйгаларны бүлеп чыгару. Төп конфликт аша ачыкланучы пьесаның төп темасы һәм автор идеясын билгеләү. Спектакльнең жанрын ачыклау.

Пьесаны уку, тикшерү, аның тема, идеясын ачыклау.Спектакльдә әйтелергә теләгән фикер турында гомуми сөйләшү. Күренеш, эпизодларны берләштерү; декорацияләр, реквизит, бутофорияләр белән репетицияләр; костюмнарда репетицияләр; музыкаль һәм ут бизәлеше белән репетицияләр; барлык сәнгати чараларны берләштерүче репетицияләр. Генераль репетиция.

Спектакль күрсәтү.

**Тема 6. Этика һәм этикет -4 сәг.**

*Теоретик дәрес:* Актёрлык этикасы (Станиславский буенча)

Актёр этикасы – сәхнә әһелләренең һөнәри этикасы.

1.Артистның җәмгыятьтә тоткан урыны (даны турында).

2.Коллективта үзара мөнәсәбәт.

3.Иҗатка карата мөнәсәбәт (рольгә, спектакльгә).

4.Һөнәри дисциплина (режиссёр белән мөнәсәбәт, репетицияләр, тренинг һ.б.)

5. Сәнгати дисциплина (спектакльгә, рольгә әзерләнү).

*Практик дәрес:*Берләшмәдәге эчке атмосфера буенча анкета уздыру.

**Тема 7. Театр культурасы нигезләре -4 сәг.**

*Теоретик дәрес:* Грим ярдәмендә сәхнә образын чагылдыру.Сәнгатьлелеккә ирешүнең бер чарасы буларак грим: гадәти, эстрада, характерлы, абстракт. Грим салу алымнары.

*Практик дәрес:* Грим салу алымнары. Сайланган пьеса геройлары өчен грим эскизлары тудыру. Шөгыльләнүчеләрнең бер-берсенә грим салуы.

*Теоретик дәрес:* Образ һәм характер турында күзаллауга тәэсир итүче төп элементларның берсе буларак костюм. “Конкретлаштырылган” һәм “универсаль” костюм. Төсе, фактурасы.

*Практик дәрес:* Сайланган пьеса өчен костюм эскизлары тудыру.

**Тема 8. Тәрбияви- укыту характерындагы мероприятиеләр - 8 сәг.**

*Теоретик дәрес:* Ял итү мероприятиеләрен оештыру һәм уздыру формалары белән таныштыру, сценарийларны эшкәртү.

*Практик дәрес:* Берләшмә эчендә һәм мәктәптә үткәрелгән ял итү мероприятиеләренә әзерләнүдә катнашу.

**Тема 9. Йомгаклау дәресләре -2 сәг.**

*Теоретик дәрес:* Бер ел эчендә өйрәтү (укыту) программасы бүлекләре буенча викторина.

*Практик дәрес:* Әти-әниләр каршында имтихан-чыгыш.

**Укыту-тематик план 5 нче ел**

| № п/п | Наименование раздела, темы | Количество часов | | | Формы промежуточной аттестации/ контроля |
|---|---|---|---|---|---|
| | | теория | практика | всего | |
| 1. | Кереш дәрес | 1 | 1 | 2 | |
| 2. | Театр тарихы | 1 | 3 | 4 | |
| 3. | Сөйләм культурасы һәм техникасы | 4 | 16 | 20 | |
| 4. | Сәхнә хәрәкәте | 2 | 18 | 20 | |
| 5. | Актерлык грамотасы | 4 | 76 | 80 | |
| 6. | Этика һәм этикет | 2 | 2 | 4 | |
| 7. | Театр культурасы нигезләре | 3 | 1 | 4 | |
| 8. | Тәрбияви- укыту характе-рындагы мероприятиеләр | - | 8 | 8 | |
| 9. | Йомгаклау дәресләре | - | 2 | 2 | |
| | Итого | 17 | 127 | 144 | |

***Бишенче уку елы программасының эчтәлеге.***

**Тема 1. Кереш дәрес -2 сәг.**

*Теоретик дәрес:* Укытуның бурыч һәм максатлары. Курс белән таныштыру. Бишенче шөгыльләнү елында иҗади үсеш перспективасы. Занятиеләрдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен кабатлау. Куркынычсызлык кагыйдәләре буенча инструктаж уздыру.

*Практик дәрес:* Белем бәйрәмендә катнашу. Театраль берләшмәнең иҗади остаханә почмагын тулыландыру.

**Тема 2. Театр тарихы -4 сәг**

*Теоретик дәрес:* Безнең эрага кадәр V гасырда иҗат иткән демократик Афина театры белән таныштыру.Өч бөек трагик: Эсхил, Софокл, Еврипид һәм комедиограф Аристофан.

*Практик дәрес:* Бирелгән темалар буенча шөгыльләнүчеләрнең реферат эшләре.

**Тема 3. Сөйләм культурасы һәм техникасы -20 сәг.**

*Теоретик дәрес:*Сөйләмнең төрле формалары: тышкы, эчке, язма, телдән, монологик, диалогик.

Фикернең эчке сөйләмдә формалашуы. Тышкы сөйләмнең язма һәм телдән булган формалары. Алар арасындагы аермалар.

Сөйләм культурасының 4 тибы: элитар, уртача әдәби, сөйләми-әдәби һәм сөйләми-фамильяр.

*Практик дәрес:* Тәкъдим ителгән әсәрләрне сөйләм культурасы типлары буенча аерырга.

*Теоретик дәрес:* Аралашуның мөһим өлеше буларак жест, мимика, интонация.

Сөйләм тавышын тәрбияләү. Үпкәләрне киңәйтә һәм кыса торган төп мускул хәрәкәте кайсы өлкәдә булуына карап,сулыш алуның 3 тибы: умрави(ключичное), күкрәк (кабырга), диафрагма(эч белән). Сөйләм процессы өчен иң файдалы саналган сулыш алуның кабырга-диафрагма тибы.

*Практик дәрес:* Сулыш алу усешенә һәм сөйләм аппаратының иреклелегенә , дөрес артикуляция, ачык дикция, логика һәм орфоэпиягә юнәлтелгән уен һәм күнегүләр.

**Тема 4. Сәхнә хәрәкәте -20 сәг.**

*Теоретик дәрес:* Аңлы рәвештә хәрәкәттәге автоматизмнан китү,бердәм процесс буларак, хәрәкәт үсешен тоемлау, жестның төгәллеге һәм оригинал колориты. Яхшы үзләштерелгән күнекмәләр нигезендә партнер белән пластик диалог һәм пластик фразаны төзи алу осталыгы – сәхнәдәге хәрәкәтне сәнгати ясаучы актер техникасының өлешләре шуннан гыйбарәт.

*Практик дәрес:* Күзәтүчәнлеккә этюдлар.

**Тема 5. Актерлык грамотасы -80 сәг.**

*Теоретик дәрес:* Актерның тамашачы алдында эшләү спецификасы.

*Практик дәрес:* Үткән уку елы спектаклен тергезү һәм берничә кат аның белән чыгыш ясау. Спектакльдән спектакльгә төгәллек һәм импровизация.

*Теоретик дәрес:* Артистның профессиональ иҗат эше турында күзаллау: роль трактовкасы белән башкаручының әйләнә-тирә дөньяны аңлавы, кабул итүе арасындагы бәйләнеш. Театр сәнгате спецификасын башкару сәнгате буларак күзаллау.

*Практик дәрес:* Этюдлар ярдәмендә үзеңнең техниканы үзләштерүеңне камилләштерү.

*Теоретик дәрес:* Пьесаның композицион төзелеш үзенчәлекләре: аның экспозициясе, төенләнеше, кульминация һәм чишелеше. Пьесадагы вакыт. Спектакльдә катнашучылар – персонажлар.

*Практик дәрес:* Сайланган пьеса өстендә эш, сюжет турында уйлану, Эш-хәрәкәт үсеше барышында борылыш, үзгәреш моментлары булып торучы төп вакыйгаларны бүлеп чыгару. Төп конфликт аша ачыкланучы пьесаның төп темасы һәм автор идеясын билгеләү. Спектакльнең жанрын ачыклау.

Пьесаны уку, тикшерү, аның тема, идеясын ачыклау.Спектакльдә әйтелергә теләгән фикер турында гомуми сөйләшү. Күренеш, эпизодларны берләштерү; декорацияләр, реквизит, бутофорияләр белән репетицияләр; костюмнарда репетицияләр; музыкаль һәм ут бизәләше белән репетицияләр; барлык сәнгати чараларны берләштерүче репетицияләр. Генераль репетиция.

Спектакль күрсәтү.

**Тема 6. Этика һәм этикет -4 сәг.**

*Теоретик дәрес:* Әңгәмә: “ ...Мин шулай уйлыйм...(яхшылык һәм яманлык турында)”.

*Практик дәрес:* Бирелгән тема буенча тест уздыру. Тестларны анализлау.

**Тема 7. Театр культурасы нигезләре -4 сәг.**

*Теоретик дәрес:* Грим ярдәмендә сәхнә образын чагылдыру.Сәнгатьлелеккә ирешүнең бер чарасы буларак грим: гадәти, эстрада, характерлы, абстракт. Катлаулы грим салу алымнары.

*Практик дәрес:* Катлаулы грим салу алымнары. Сайланган пьеса геройлары өчен грим эскизлары тудыру. Шөгыльләнүчеләрнең бер-берсенә грим салуы.

*Теоретик дәрес:* Образ һәм характер турында күзаллауга тәэсир итүче төп элементларның берсе буларак костюм. “Конкретлаштырылган” һәм “универсаль” костюм. Төсе, фактурасы.

*Практик дәрес:* Сайланган пьеса өчен костюм эскизлары тудыру.

**Тема 8. Тәрбияви- укыту характерындагы мероприятиеләр - 8 сәг.**

*Теоретик дәрес:* Ял итү мероприятиеләрен оештыру һәм уздыру формалары белән таныштыру, сценарийларны эшкәртү.

*Практик дәрес:* Берләшмә эчендә һәм мәктәптә үткәрелгән ял итү мероприятиеләренә әзерләнүдә катнашу. Хаталарны аерып күрсәтү.

Экскурсия. Очрашу. Культпоходлар.

**Тема 9. Йомгаклау дәресләре -2 сәг.**

*Чыгарылыш имтиханы.*

Чыгарылыш имтиханына нәтиҗә өч билгегә нигезләнеп чыгарыла:

- спектакльләрдә катнашу(саны һәм сыйфаты);

- телдән җавап һәм этюдның импровизацияләп башкарылуы;
- имтихан-концертта сәнгатьле уку репертуары һәм актер эшләренең башкарылуы.

**<u>Программаны гамәлгә ашыруның оештыру-педагогик шартлары</u>**

<u>Материаль-техник тәэмин ителеш:</u>

Занятиеләр санитар-гигиеник нормаларга( температура режимы, яктылык режимы һ.б.) туры килүче киң, җилләтелгән бинада уздырылырга тиеш. Кабинет көзгеләр белән җиһазландырылырга тиеш. Дәресләрдә көзге күнегүләрнең дөрес үтәлешен тикшерү , грим салу өчен кирәк. Декорацияләр, костюмнар, грим кебек театраль атрибутиканың булуы да бик мөһим.

<u>Мәгълүмати тәэмин ителеш:</u>

Нәтиҗәле эш өчен фонотека, видеоматериаллар, күрсәтмә әсбаплар, укыту, фәнни-методик, диагностик, дидактик материаллардан файдалану, интернет технологияләре, укытуның техник чаралары: магнитофон, видеомагнитофон, телевизор, сәхнә һәм музыкаль материалларны эшкәртү өчен персональ компьютер куллану зарури.

**Методик, дидактик тәэмин ителеш**

Программаны уңышлы тормышка ашыру максатыннан түбәндәге дидактик материаллар эшләнде һәм кулланыла:

*Иллюстратив һәм демонстрацион материал:*

- театр тарихы темаларына карата иллюстрация, репродукцияләр;
- “Сәхнә костюмы”, “Театраль грим” темалары буенча иллюстрацияләр;

*тарату материаллар:*

- “Тавыш өстендә практик эш” темасы буенча күнегү карточкалары;
- “Театр тарихы” бүлегенә караган биремнәр белән карточкалар;

*программаны үзләштерүне тикшерүгә материаллар:*

- зачёт-дәресләр өчен биремнәр белән карточкалар, программа бүлекләре буенча имтихан-чыгышлар;
- иҗади биремнәр;
- “Театр тарихы” бүлеге буенча тестлар;
- кроссвордлар, викториналар һ.б.

*интернет-материаллар*

*уен, күнегү, психологик тренинглар, әңгәмә, сценарийлар эшкәртмәләре.*

**Әдәбият**

*Педагоглар өчен әдәбият исемлеге:*


1. Методическое пособие. В помощь начинающим руководителям театральной студии, Белгород, 2003.
2. Любовь моя, театр(Программно-методические материалы) – М.: ГОУ ЦРСДОД, 2004. – 64с.(Серия “Библиотечка для педагогов, родителей и детей”).
3. Голубовский Б. Путь к спектаклю. – М.:ВЦХТ, 2005.
4. Збруев Н. Ритмическое воспитание актера. М.: ВЦХТ, 2003.
5. Кидин С.Ю. Театр-студия в современной школе: программы, конспекты занятий, сценарии. – Волгоград: Учитель, 2009.
6. Логинов С.В. Школьный театр миниатюр: сценки, юморески, пьесы. – Волгоград: “Учитель”, 2009.
7. Попов П.Г. О методе. Театральная педагогика. Режиссура. – М.: ВЦХТ,2005.
8. Попов П.Г. Режиссура. О методе. – М.: ВЦХТ,2003.
9. Царенко Л. От потешек к пушкинскому балу. – М.:ВЦХТ, 2002.
10. Шарова И.И. Развиваем речь, или маленький оратор. – Ростов –на-Дону: “Феникс”, 2008.
11. ЩеткинА.В. Театральная деятельность в детском саду. – М.: “Мозаика-Синтез”, 2007.

12. Петерсон Л., О Коннер Д. Дети на сцене – как помочь молодому таланту найти себя. - Ростов –на-Дону: “Феникс”, 2007.
13. Лоза О. Актерский тренинг по системе Станиславского. Упражнения и этюды.- М.:АСТ,2009.
14. Костюк М.Е. Риторика. – М.: “Просвещение”, 2008.
15. Кидин С.Ю. Театр-студия в современой школе. - Волгоград: Учитель, 2009.
16. Гальцова Е.А. Детско-юношеский театр мюзикла.- Волгоград: “Учитель”, 2009.
17. Р. Нуриев. Сәнгатьле уку. Методик ярдәмлек.- Казан: 2000.- 152б.
18. Р.Нуриев.Татар драматургиясенең лингвистик поэтикасы.-Казан: “Печатный двор” нәшр., 2002.-324б.

*Укучылар һәм ата-аналар өчен әдәбият исемлеге:*

1. Граник Г.Г., Л.А.Концевая. Драматурги, драматургия, театр. – М.: Владос, 2001.
2. Татар театры(1906- 1926).- Тулыландырылган 2 нче басма.- Казан: Мәгариф, 2003
3. Татар энциклопедиясе: 6 томда / Баш мөхәррир М. Х Хәсәнов, җаваплы мөхәррир Г. С. Сабирҗанов.- Казан: “ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты» дәүләт учреждениесе.

**Кушымта**

Дәрес конспекты

**Тема: “ Мәкаль, әйтем, канатлы сүзләргә этюдлар”**

***Занятиенең максаты:*** театр сәнгате чаралары ярдәмендә балаларның сәләтләре һәм талантларын ачу, театраль эшчәнлеккә тарту юлы белән, аларның ял сәгатьләрен оештыру өчен шартлар тудыру.

***Занятиенең бурычлары:***

1. Белем бирү: Халык авыз иҗаты: мәкаль, әйтем, канатлы сүзләргә карата иҗади игътибарлылык булдыру, иҗади фикерләүне, актёрлык сәләтләрен үстерү.
2. Акыл сәләтен үстерү: балаларда логик яктан дөрес сөйләм тәрбияләү.
3. Тәрбияви: югары сөйләм культурасына ия, рухи яктан бай шәхес тәрбияләү, халык авыз иҗатына мәхәббәт тәрбияләү, укучыларга әхлак тәрбиясе бирү.

**Методлар:** әңгәмә, уен, күрсәтмә, этюдлар.

**Формалар:** төркемләп, индивидуаль.

**Материаль-техник тәэмин ителеш:**

Кабинетта көзгеләр белән җиһазландырылырга тиеш көзге. Декорацияләр, костюмнар, грим кебек театраль атрибутиканың булуы да бик мөһим. Үкытуның техник чаралары: сәхнә һәм музыкаль материалларны эшкәртү өчен персональ компьютер куллану зарури.

**Дәреснең тибы:** катнаш.

**Дәрес барышы.**

***I. Кереш өлеш.***

Укучыларга дәреснең темасы хәбәр ителә, иҗади игътибарлылыкның актёрлар өчен ни кадәр мөһим икәнлеге ассызыклана. Иҗади игътибарлылык – аның ярдәмендә актер үзенең фантазиясе белән бирелгән объектны үзе өчен мөһим, кирәкле, кызыклы итәрдәй игътибарлылык ул. Укучыларга кызыксызны кызыклыга әверелдерү бурычы,көнкүрештә табигый, кызык булмаган нәрсәләрне кызыклыга әверел дерү максаты куела. Моның өчен фантазияне эшкә җигүнең мөһим икәнлеген аңлау бурычы йөкләнелә.

***II. Кабатлау.***

1. Актёрның төп коралы – сүз икәнен истә тотып, дәрес артикуляцион гимнастикадан башлана.
2. Дөрес сулыш алуга юнәлдерелгән “Шар” уены.
3. Образга керүгә юнәлдерелгән “Кадак” һәм башка этюдлар.
4. Эмоцияләрне дөрес белдерергә өйрәтүче ,
5. Тавыш белән идарә итәргә өйрәтүче күнегүләр үткәрелә.

***III. Яңа материалны өйрәнү.***

Әйтем — сүзнең бизәге, мәкаль — сүзнең җиләге. Канатлы сүзләргә килгәндә исә, кеше талантлырак булган саен ул әйткән хикмәтле сүзләрнең күбесенә канатлар чыга. Аның сүзе бөтен илгә тарала. Менә шундый сүзләрне канатлы сүзләр дип атыйлар. Укучыларга әйтем, мәкаль, канатлы сүзләргә мисаллар китереп, аларның телебезгә никадәр бизәкләр салуын аңлатып кителә.

Бу хикмәтле сүзләр кешеләр тормышында мөһим роль уйный. Аларның һәрберсендә аерым фикер, тирән мәгънә дә яшеренгән. Балалар белән бу темага әңгәмә оештырыла. Мәкаль, әйтем, канатлы сүзләр язылган табличкалар таратыла. Бергәләп анда яшеренгән фикерне ачыклау максаты куела. Балалар әйтем, мәкаль, канатлы сүзләргә характеристика бирәләр. Үзләренә җирәбә аша эләккән хикмәтле сүзләргә этюдлар уйлап чыгаралар. Бу юлда аларга дөрес юнәлеш бирү укытучының бурычы булып тора.

Театр түгәрәгенә йөрүче укучының үзе күрсәткән образга тулысынча әверелү сәләте булуы зарур.

Этюдларда бирелгән сүзләрнең мәгънәсе ачылдымы - балалар бер-берсенең фикерләрен тыңлыйлар, моңа үз мөнәсәбәтләрен белдерәләр.

Мәкаль, әйтем, канатлы сүзләргә сүзсез һәм сүзле, парлы, ялгыз һәм күмәк этюдлар куела.

Педагог анализы ясала.

***IV. Йомгаклау***

Дәрескә нәтиҗәләр ясала, педагог тарафыннан укучыларның эшчәнлеге бәяләнә.

Киләсе дәрестә дә әлеге теманың дәвам ителәчәге ассызыклана.

*Дәрес конспекты*

**Тема: «Ясалучы картинаның әдәби әсәр жанры белән бәйләнеше»**

**(«Связь сценической картины с жанром литературного произведения»)**

**Шөгыльнең максаты (цель занятия):** акыл үсеше белән сөйләм теленең үсешен үстерү, персонажлар сөйләмен сәнгатьле итеп сөйләү өстендә эшләү, аваз культурасы, интонацияле сөйләү тәрбияләү.

Развитие речи с одновременной работой над развитием интеллекта, работа над художественным воспроизведением речи персонажей в соответствии с жанром литературного произведения, формирование звуковой культуры интонационной речи.

**Максатлар (задачи):**

4. Белем бирү: укучыларда сәхнә образы турындагы белемнәрне ныгыту; әдәби әсәрләр жанрлары турындагы белемнәрне киңәйтү;
   Ообразовательные: закрепление знаний у учащихся о сценической образности; расширение знаний о жанрах литературных произведений.
5. Акыл сәләтен үстерү: анализ нәтиҗәләрен куллану, әдәби әсәрне сәхнә картинасын булдыруда тикшерү, акыл сәләтләрен үстерү, логик дөрес татар сөйләме формалаштыру сәләтен үстерү.
   Развивающие: развитие способности использовать результаты анализа, исследования литературного произведения в создании сценической картины, развитие умственных способностей, формирование логически правильной татарской речи.
6. Тәрбияви: югары сөйләмгә, иҗатка, театрга, туган телгә булган мәхәббәткә ия булган рухи бай шәхес тәрбияләү.
   Воспитательные: воспитание духовно богатой личности, обладающей высокой культурой речи, любви к творчеству, к театру, к родному языку.

**Методлар:** әңгәмә, уен, күрсәтмә, этюдлар.

**Формалар:** төркемләп, индивидуаль.

**Дәреснең тибы:** катнаш.

## I. Кереш өлеш.

Укучыларга дәреснең темасы хәбәр ителә, ясалучы картинаның әдәби әсәр жанры белән бәйләнеше никадәр мөһим икәнлеге ассызыклана.

Ясалучы картинаның әдәби әсәр жанры белән бәйләнеше бик зур. Укучыларга әдәби әсәр жанрларын барлау, аларны белүнең дәрәҗәсен үстерү максаты куела.

## II. Кабатлау.

6. Актёрның төп коралы – сүз икәнен истә тотып, дәрес артикуляцион гимнастикадан башлана.

7. Дөрес сулыш алуга юнәлдерелгән "Шар" уены. Образга керүгә юнәлдерелгән "Кадак" һәм башка этюдлар.

## III. Шөгыльнең төп өлеше

**Тәрбияче:** Балалар! Кунакларыбыз үзләрен озак көттермәсләр, килеп тә җитәрләр инд е . Без бернәрсәне дә онытмадыкмы?

**Балалар:** (җаваплар)

-бөтен җирне җыештырдык

-тәмле әйберләр пешердек

-матур итеп киендек

**Тәрбияче:** Димәк без кунакларны каршы алырга әзер?

**Балалар:** Әйе! («Күчтәнәч» тапшыруының көе яңгырый, кунаклар керә)

**Кунаклар:** Исәнмесез, балалар!

**Балалар:** Рәхим итегез, түрдән узыгыз!

**Тәрбияче:** Исән-сау гына килеп җиттегезме? Бик хәзер армадыгызмы? Без сезнең киләсен алдан белеп, көтеп тордык.

**Дәү әни:** Каян белдегез?

**Тәрбияче:** Татар халкында шундый юраулар бар бит.

**Балалар:**

-Мендәр ишелсә, кунак килә!

-Самавар җырласа, кунак көт!

-Саескан ишегалдына төштеме - кунак килә*!*

-Песи битен юса да, кунак килә*!*

-Кашык идәнгә төшсә дә кунаклар киләчәк*!*

**Тәрбияче***:* Менә бездә нәкъ шулай булды да. *(*Кунакларны утыртабыз *)*

**Тәрбияче***:* Бүген безгә килгән кунакларны таныдыгызмы*?* Алар сезгә танышмы*?* Ничек *?*

**Балалар***:* « Күчтәнәч» тапшыруы буенча .

**Тәрбияче***:* Әйе, хөрмәтле Дәү әни, Дәү әти, Йомшаккай*!*

Без сезнең тапшыруларны яратып карыйбыз, көтеп алабыз.

Кадерле кунаклар*!* Чәй табынына рәхим итегез*!*Сез килүгә гаҗәеп тәмле әйберләр пешереп куйдык. Аларны балалар үзләре әзерләделәр. Табында матур җырлар, кызыклы шигырьләр, күңелле биюләр, серле әкиятләр, шаян уеннар*!* Ял итеп, сыйланып утырыгыз эле.

***МУЗЫКАЛЬ ТӘНӘФЕС.*** ***<u>ҖЫР: «Гармун уйныйм»</u>***

**Малай***:* Татарстан - үз илебез,
Безнең газиз җиребез.
Безнең газиз җиребезнең
Балалары инде без*!*

**Кыз***:* Йөри безнең бакчага
Бик күп төрле балалар,
Төрле-төрле телләрдә
Сөйләшә белә алар.
«Дустым» сүзен дүрт телдә

Өйрәндем мин үзем дә
Әйтә беләм дүрт телдә
«Исәнмесез!» сүзен дә.
**Тәрбияче:**Безнең балалар бакчасына бүгенге көндә ------- бала йөри. Шулардан ------- татар баласы,------ рус балалары, ----- милләт баласы. Алар үзара дус-тату, матур итеп аралашып үсәләр. *Үз* милләтләре белән горурланалар, башка милләт кешеләренә хөрмәт белән карыйлар, бер гаилә булып яшиләр.
**1 укучы:** Аю идәнгә егылган,
Аның бер аягы сынган.
Барыбер ташламыйм аны
Бик яратам мин аюны.
**2 укучы:** Әминә елый үкереп,
Тубым суга төште дип.
«Чү, Әминә, елама,
Туп батмый ул елгада...»
**Тәрбияче:** Әкият сөйлим сезгә,
Тезеп сүзләрен сүзгә.
Ә сез отып калыгыз,
Күңелегезгә салыгыз.
Әкият төше - алтындыр
Аңлаганга акылдыр.
Әкият сөйлим сезгә,
Әкият ул күп төрле:
Тормышның үзе шикелле
Катлаулы , кызык, серле.

**А.Алиш: «Куян кызы» әкиятен сәхнәләштерү**

**3 укучы:** Әтәч бик иртә тора
Канат кагып кычкыра.
-Кикрикүк, кикрикүк!
Тор иртәрәк, эшең күп!
**Тәрбияче:** И-и, Булат! Син әбинең әтәче турында әйтәсеңме? Алар бит әле икәү! Чукмар белән Тукмар!

***А.*Алиш «Чукмар белән Тукмар» әкиятен сәхнәләштерү**

**Тәрбияче:** Балалар, Алиш абыегыз бу әкиятләрне сезнең өчен язган - зурларның сүзен тыңлап үсәргә, дус булырга чакырган.
**Тәрбияче:** Их, безнең татар кызлары
Ак калфак киюләре.
Калфак кигән чибәрләрнең
Ягымлы көлүләре.
Кызлар! Сезне бик матур бии диләр.
Биеп күрсәтегез әле.
**4 укучы:** Өйгә кайтсам - өй балкыган
Өйгә нур иңгән!
Ерак юлны якын итеп
Әбием килгән!

**(Дәү әни белән Дәү әтине барып кочаклый)**

**5 укучы:** Ә мин дәү әнинең коймакларын яратам!
Коймагы да коймагы:
Агып тора каймагы
Табада пешеп тора
Табынга төшеп тора.

Кайнар- яланкул тотма!
Тәмле- телеңне йотма.
Син телеңне йотсаң әгәр,
Кем рәхмәт әйтер әбигә?
**5 укучы:** Ә мин дәү әтине яратам!
**МИНЕМ БАБАЙ**
Читек-кәвешләрен киеп,
Башка түбәтәен элеп,
-Әссәләмәгәләйкүм!- диеп
Сәлам бирә өйгә кереп.
Тыйнак кына үтә түргә
Һәр кешегә башын иеп
Кулларын өскә күтәрә
-Өйгә дога кылыйк! –диеп
Бала-чаганы онытмый
Чыга хәер өлешләре.
Кесәсендә йөри аның
Конфет, өрек җимешләре.
Тәмле итеп сүзен сөйләр
Моңлы итеп аять көйләр.
Ак сакаллы, ак күңелле
Бабам белән ямьле өйләр!
**Тәрбияче:** Ә менә Алиянең шигыре песи турында.
**ПЕСКӘЕМ.**
Бар минем пескәем
Бик акыллы дускаем.
Ап-ак йомшак күлмәге
Бизи безнең бүлмәне.
Күзләре ялт-йолт итә
Мыегы җиргә җитә.
Үзен *бик* яратам мин
Аның белән ятам мин.
Тик ул бик иртә тора,
Мияу, диеп кычкыра.
Мияу,мияу,мияу ди,
Мин күптәннән уяу ди.

***ҖЫР: «Гармун уйныйм»***

***1.***Гармун уйныйм, гармун уйныйм,
Һаман гармун уйныйм мин.
Остарып җиткәч, барсын да
Биетергә уйлыйм мин.
Учларыңны шапылдатып,
Чәчләреңне сыпыр да,
Тыпыр-тыпыр, тыпыр-тыпыр,
Тыпыр-тыпыр, тыпырда.
***2.***Әй, бии итек-читекләр,
Әй, биим мин, биим мин.
Минем кебек шәп гармунчы
Юктыр диеп уйлыйм мин.

***А.*АЛИШ. «КУЯН КЫЗЫ»**

***(Катнашалар: әни куян, куян кызы, тиен)***

**Доктор Айболит**

Бер соры куянның
Узе төсле ук озын колаклы,
Бик иркә бик кадерле кызы булган.
Ул аны бик-бик ярата икән.
Көннәрдән бер көнне.
Куян иркә кызына өр-
Яңа киез итекләр алыпкайтып биргән.
**Әни куян*: (***итекләрне тотып керә***)***
Кызым, кызым, син кайда? Мә, бәбкәем, ки, аякларың туңмасын, сызламасын.
**Куян кызы*:*** Әнием, бик зур рәхмәт.***(***кия***)*** Ай, аякларыма
шундый жылы, рәхәт.***(***йөреп карый***)*** И,уңайсыз <u>*ич*</u>
бу . Йөгереп тә булмый, сикереп тә булмый.***(***итеген сала, яшереп куя***)***
Әнием курмәсен әле.
**Әни куян*:*** <u>Кызым</u>, нигә итекләреңне салдың? ***(***табып алып бирә***)*** Мә, кий тизрәк.
**Алып баручы*:*** Әнисе кигезә, ул салып ташлый икән.Кар
өстеннән дә, боз өстеннән дә яланаяк йөгергән.
Бер көн шулай йөгергән, ике көн шулай йөгергән, өченче көнне елый-елый, аксый-аксый әнисе янынакилгән.
**Куян кызы*:***
Кызым,кызым, якты йолдызым. Синен аякларың шешкән ич. Инде нишләргә? Бу б аланы кая алып барырга? Ничек терелтергә?
**Алып баручы*:*** Аларга ярдәмгә тиен килгән.
**Тиен*:*** Исәнмесез, куяннар! Сезгә нәрсә булды?
**Әни куян*:*** Кызымның аяклары шеште.
**Тиен*:*** Сезгә доктор Айболитка барырга кирәк, ул сезгә дару бирер.
**Куяннар*:*** Рәхмәт!
**Алып баручы*:*** Куян кызын житәкләгән дә, доктор Айболитка киткән . Доктор Айболит аларны чират сыз керткән.
**Әни куян*:*** Доктор Айболит, кызымнын аяклары шеш*те.*
**Айболит*:*** Кая, карыйм әле, нишләп шеште икән? Куянкай, наянкай, кайда болай йөрдең?
**Куян кызы*:*** Доктор Айболит, мин гаепле, әнием алып биргән итекләрне кимәдем дә аякларым туңды.
**Айболит*:*** Менә болайрак утыр әле. ***(***карый***)***
Әниеңнең сүзен тыңларга,
Кирәк һәрчак туганкай.
Аякларың ай-һай-һай,
Дару сөртмичә булмый.
**Куян*:*** Ай, доктор Айболит,
Рәхмәт, доктор Айболит.
**Айболит*:*** Бирәм дускай бер киңәш,
Терел генә тизерәк.
Шундый суык көннәрдә
Итек кияргә кирәк!
**Куян*:*** Ай, доктор Айболит
Рәхмәт доктор Айболит.
**Әни куян*:*** Зур рәхмәт, доктор Айболит!
**Айболит*:*** Сәламәт булыгыз!
**Алып баручы:** Өч көн дигәндә, куян баласының аягы төзәлгән . Ул инде киез итеген бер дә салмый киеп йөри икән.
**Тәрбияче*:*** Ә хәзер сүзне Казан кунакларына бирик әле

**(КУНАКЛАР СҮЗ АЛА)**

**Тәрбияче*:* *(*йомгаклау*)***
**Бала*:*** Безнең бакча кунакчыл***:***
Якты чырай**,** такта чәй дип
Каршы ала кунакны**,**
Ата-баба гадәтләрен
Без дә дәвам итәрбез**,**
Тагын кунакка килегез**,** көтәбез***!***

*Дәрес конспекты*

**Тема: “Бәйләнешле образлы сөйләмне үстерүче сүзләр белән уеннар”**
**(Игры со словами для развития образной речи)**

**Цель занятия:** Развивать воображение детей, умение использовать в описании точные по смыслу слова и образные выражения.

**Задачи:**

***Обучающие:***
- Совершенствовать диалогическую и монологическую формы речи.
- Упражнять детей в согласовании слов в предложении.
- Обобщить и систематизировать знания.
- Активизировать словарный запас.

***Развивающие:***
- Приучать детей к самостоятельности суждений.
- Совершенствовать умение составлять рассказы.
- Развивать творческое воображение, фантазию, речь, мышление, умения видеть, чувствовать, обсуждать .

***Воспитательные***:
- Воспитывать устойчивое внимание, наблюдательность, формировать способность к анализу и синтезу.
- Формировать у детей взаимоотношения сотрудничества при решении учебных задач, воспитывать умение сопереживать успехам и неудачам товарищей.
- Воспитывать умение слушать друг друга.

**Методы**:
- сравнения;
- игры;
- объяснительно-иллюстративный (беседа, рассказ);
- частично – поисковый;
- наглядно – слуховой.

**Форма занятия:** групповое занятие.

**Оборудование и материал:**
Телевизор (игрушка), картинки (изображения героев сказок, приславших свои вопросы на игру), волшебная коробочка (с золотым гребнем), «цветик-семицветик».

**План занятия**

1. Организационный момент
2. Разминка
а) артикуляционная гимнастика
б) дыхательная
в) скороговорка
г) игры со словами для развития образной речи
3. Работа с произведениями
4. Заключительная часть

**Ход занятия:**

**I. Организационный этап.**

**Педагог*:***

Хәерле көн, балалар! Без алдагы дәресләрдә сөйләмнең әһәмияте, аның темпы, ритмы турында сөйләшкән идек. “Образлы сөйләм” төшенчәсен дә тикшердек. Бүгенге дәресебез безнең образлы сөйләмебезне баетачагына бер дә шигем юк! Хәзер үткәреләчәк “Нәрсә? Кайда? Кайчан?” уенында сез моңа һичшиксез инанырсыз.

Бүгенге уеныбызга сорауларны безнең яраткан әкият геройларыбыз җибәргән.

Ә бүгенге уеныбызны үткәрергә әлеге сандыкчыкта ятучы предмет ярдәм итәр. Аның нәрсә булуын сез үзегез белергә тиеш. (Балалар төрле сораулар биреп, сандыкчыкта ни ятуын аңларга тиеш.

Балалар:

- Ул табигать системасымы? – Әйе
- Нинди төстә? – Төрле төстә.
- Нинди формада? – Түгәрәк
- Нинди функция үти? – Кешелзәргә шатлык бүләк итә.Туган көннәренә бүләк итәргә мөмкин.
- \Чәчәк.
- Әйе, ул чыннан да чәчәк! Ул тылсымлы җиде төсле чәчәк!Аның ярдәме белән без сәяхәткә кузгалырбыз.

Ләкин башта без разминка ясарга тиеш.

**II. Разминка.**

- Актёрның төп коралы – сүз икәнен истә тотып, дәрес
- артикуляцион гимнастикадан башлана.
- Дөрес сулыш алуга юнәлдерелгән “Шар” уены.
- Образга керүгә юнәлдерелгән “Кадак” һәм башка этюдлар.
- Эмоцияләрне дөрес белдерергә өйрәтүче ,
- Тавыш белән идарә итәргә өйрәтүче күнегүләр үткәрелә.

**Педагог:** Афәрин, балалар! Инде сәяхәткә кузгалсак та ярый!

**III. Яңа материалны өйрәнү.**

**Педагог.** Сәяхәт башлансын өчен, безгә тылсымлы чәчәгебезнең таҗын өзәргә кирәк. (Балалар өзә, музыка яңгырый)

Күрәсезме, таҗ гади генә түгел, анда цифра язылган. Ул нинди цифра?

**Балалар.** Ике!

**Педагог.**Ике саны астында – мәкальләр!

Бу сорауны сезгә Убырлы җибәргән, балалар!

Сезгә уйлап торырга вакыт бирелми, тиз генә мәкальләрне дәвам итәргә тиеш буласыз!

***Бироем: мәкальләрне әйтеп бетер!***

- Укусыз белем юк,

*(Белемсез көнең юк,)*

- Уку төбе — (*туку (кат-кат әйтеп күңелгә сеңдерү).*
- Укы да бел, *(уйна да көл,)*
  - Уйнавын уйна, *(Йомышны да уйла.)*
- Укыдым дип әйтмә, (*аңладым дип әйт.)*
- Укып белү бер башка,

(*Күреп белү бер башка.)*

- Укысаң белерсең,

*(Укымасаң бөләрсең.)*

- Эшләми укуның кадерен белмәсәң, *(эшли-эшли укырсың!)*

  **Педагог.** Афәрин, балалар! Сез барысын да беләсез!Инде киләсе таҗны өзик! Анда нинди сан?

**Балалар.** Биш!

Сезгә каршы шаян Шүрәле уйный, балалар! Ул “Кәҗә белән Сарык” әкияте сурәтләнгән пленканы өзгәләп ташлаган. Сез аны дөрес итеп җыярга, һәм әкиятне сөйләп бирергә тиеш!

***Бироем:*** «**Диафильм**»).

*Балалар биремне үтиләр.*

**Педагог.**Ай, нинди акыллылар сез! Ә без сәяхәтне дәвам итәбез! Киләсе таҗны өзегез! Анда нинди сан?

**Балалар.** Алты!

**Педагог.** Бу сорауны сезгә Албасты үзе җибәргән. Күрәсезме, ул сезгә бер тылсымлы тартма да калдырган. Игътибар! Тартма эчендә – алтын тарак!

Әгәр сез бу таракның нинди әкияттән икәнен әйтеп бирә алсагыз, ул үз әкиятенә кире кайтыр! Я, сезнең җавапны көтәм!

**Балалар.** “Су анасы”!

**Педагог.** Монда иң акыллы балалар гына җыелган. Кем миңа әкиятне матур итеп сөйләп бирер?

*Баллаар әкиятне сөйлиләр.*

**Педагог.** Афәрин, балалар! Нәкъ шушы урында әлеге әкият буенча этюдлар күрсәтсәк тә ярый! Бу безең сәяхәтебезнең матур нәтиҗәсе булыр!

*Балалар әкият буенча этюдлар куялар.*

**IV. Заключительная часть.**

**Педагог:** Вокаль-интонацион сәнгатьлелек чаралары башкарылучы җырның характерына, аның образына турыдан-туры йогынты ясый. Һәрбер җыр үзенчәлекле, кабатланмас, якты һәм тәэсирле җырга әверелә. Ә интонацияләр, кечкенә тылсымчылар кебек. Алар көйнең характерын үзгәртәләр, сәнгати образ тудырырга, көйне генә түгел, текстны да сәнгатьле итеп яңгыратырга ярдәм итәләр. (Җавапларны җентекләп тикшерү һәм аларны гомумиләштерү бара).

**Педагог:** Бүгенге шөгыль сезгә ошадымы? Нинди яңалыклар белдегез? Мин сезнең бүген алган белемнәрегез сезгә яңа җырлар өстендә бик күп эшләргә ярдәм итәр дип уйлыйм.

**V. Йомгаклау**

Дәрескә нәтиҗәләр ясала, педагог тарафыннан укучыларның эшчәнлеге бәяләнә. Киләсе дәрестә дә әлеге теманың дәвам ителәчәге ассызыклана.